Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 19 (1435) 19 май 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

1995 елның июленнән башлап чыга

8

Төркиянең Искешәһәрендә яшәүче милләттәшебез Айзирәк Гәрәева-Акчура әсәрләре аша мөһаҗирләр тормышын күзаллыйбыз.

12

Ире, атаклы кылкаләм остасы Харис Якуповка иҗат өчен барлык шартлар тудырган, үзе дә чын сәләткә ия рәссам ханым була ул.

14

Авылдан килеп, сәхнә үрләрен яулаган баянчы Фәнис Гыйльметдинов бихисап җырчыларның, сәнгатькярләрнең хөрмәтен яулый.

Шәҗәрәбез тирән тамырлыдыр, Ябалдашын саклыйк бергәләп!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Г.Камал театрының Кече залында данлыклы щепкинчы артистлар – Наил Дунаев һәм Нәҗибә Ихсанованы искә алу кичәсе узды.

● Курган өлкәсенең янгыннан коточкыч зыян күргән Эчкен авылы укучылары Актаныш районында урнашкан Бүләк лагереның Тел сменасында ял итәчәк.

● Минск өлкәсенең Червеня районында Белоруссия, Татарстан, Кыргызстан, Казахстан мәгариф учреждениеләре укучылары катнашында Габдулла Тукай иҗатына багышланган халыкара конкурс узды.

● «Казан Кремле» музей-тыюлыгының Ислам мәдәнияте музеенда беренче басма Коръән чыгуга 220 ел тулуга багышланган «Казан Коръәне» күргәзмәсе ачылды.

● «Ярдәм» фонды вице-президенты Мәликә Гыйльметдинова Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Бердәмлек» медале белән бүләкләнде.

● Башкортстанның З.Биишева исемендәге «Китап» нәшриятында тарихчы Фәрит Вахитовның легендар дивизия командиры Миңнегали Шәйморатов турында китабы басылып чыкты.

● Ставрополь краендагы Кече Барханчак авылы мәдәният йортында «Көньяк Сабантуй» бәйрәме оештырылды.

● Ульяновск өлкәсенең Димитровград шәһәрендә Ринат Илкиннең Мәләкәс районы Атнагыл авылына багышланган яңа китабын тәкъдим итү кичәсе узды.

● Мәскәү өлкәсенең Волоколамск шәһәрендә Мөселман рухи-агарту үзәге ачылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Александр АЛЕКСАНДРОВ, «Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы» мөдире:

«Еллар узган саен саннар да үзгәрә. Минем балачакта мәктәп дәреслегендә «Советлар Союзы 20 миллион кешесен югалткан» дип язылган иде. Хәзерге рәсми саннар – 27 миллион. Эзтабарлар эшли, архивларда сакланган документлар ачыла... Җиңүнең 75 еллыгына музейны төзекләндергәндә, 175 мең кеше хәбәрсез югалган, дип санала иде, ә менә үткән елга инде 21 мең кешенең язмышы ачыкланды».

СЫНАМЫШЛАР

Май ае салкын килсә, игенгә туклык булыр, чебенгә юклык булыр ● Яз көне элек булмаган җирдән чишмә бәреп чыкса, җәй яңгырсыз килер ● 19 майда кыяр һәм борчак чәчәләр; бу көнне чык мул төшсә, кыяр уңа ● 22 майда яңгыр яуса, уңышлы ел фаразлана; бу көнне бәрәңге утырталар ● 24 майда томан төшсә, юеш булса, яңгырлы җәй көтелә ● 25 майда таң кызарып атса, җәй эссе була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 27 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 55 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **16 сәгать 28 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **23 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **26 майда 16 сәгать 51 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

19 май – шагыйрь, мөгаллим Нәҗип Сибгатулла улы Думавиның (Тахтамышев) тууына 140 ел (1883–1933);

– график, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Нажия Хәмит кызы Галләмовага 70 яшь (1953).

20 май – актёр, режиссёр, Татарстанның халык артисты Айдар Садри улы Хафизовның тууына 80 ел (1943–2020);

– сәнгать белеме докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Земфира Нурмөхәммәт кызы Сәйдәшевага 85 яшь (1938).

23 май – актёр һәм режиссёр, Татарстанның атказанган артисты Сәет Садри улы Булатовның тууына 125 ел (1898–1970).

24 май – Татарстанның атказанган укытучысы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор Флёра Садри кызы Сафиуллинаның тууына 85 ел (1938–2011).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Майның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 23-25 май.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(19-27 май)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген шәүвәл аеның 29 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Вахит ИМАМОВ

Башкортстан тарихы – башкортныкы гына түгел!

Без Башкортстан тарихында татар халкы тоткан урын турында моңа кадәр дә байтак яздык инде. Уфа мөтәгалимнәре юрганны гел үз якларына гына тартмасын өчен һәм аннан да бигрәк «Башкорт гаскәре» дип игълан ителгән җәйдаклы полкларның ким дигәндә 60-70 процентын татар-мишәр-типтәр ирләре тәшкил итүен исбатлау максатыннан да бик күп сөрән салдык. Шул нисбәттән газетабызда 1812 елгы Ватан сугышында дан алган Минзәлә өязе яугирләренең һәм аерым рәвештә бүген Актаныш районында исәпләнүче авыллардан шул яуга киткән 100 җәйдакның исемлекләре дә дөнья күрде. 1773 елда кузгалган Пугачев явы барышында да төп көчне башкортлар түгел, бәлки нәкъ татар ирләре, татар отрядлары тәшкил итүе хакында да дистәләгән язмалар басылды. Әмма ни кызганыч, ут күршеләрдә һаман башкортларны гына күккә чөю, ә татарны пәрдә артына этеп, Башкортстанның 25-30 лап районында 4-5 гасыр буе чәчәк аткан татар телен дә – «башкорт теленең төньяк-көнбатыш диалекты» дип дәгъва итәргә маташу дәвам итә.

Уфа мөтәгалимнәренең, нәкъ иске риваятьтәге тискәре хатыннар шикелле, болындагы үләнне чабып алынган, дип түгел, ә кыркылган, дип «исбат итәчәге» һәм елгага куелган басма өстенә менгән тискәре кәҗә тәкәсе кебек кире чигенмәячәге безгә мәгълүм инде. Ләкин «Гали – үз эшендә, Вәли – үз эшендә» дигән тәкрарлаудагы кебек, без дә үз дәгъваларыбыздан кире кайтырга җыенмыйбыз һәм, менә, яңа дәлил итеп, 1771-1772 елларда узган Польша походына тукталырга булдык.

Чын дөресен әйткәндә, күкрәк сугып шапырырдай һәм һичбер милләтне дә данга күмәрдәй сәфәр түгел инде ул. Моңа кадәр рус дәүләте изүе астында газап чиккән поляк крестьяннары азатлык яулау өчен дип, 1771 елда яңа бер восстаниегә күтәрелә. Аларны канга батыру өчен, Әби патша 1771 елның 8 октябрендә Уфа провинциясеннән дә 10 партия җәйдак озату турында фәрман игълан итә. 1771 елның 16 декабрена алар тупланып та бетә. Дүрт юлда исәпләнүче төрле волостьлардан 3000 җәйдак җыеп һәм аларны 300 әр яугирле командаларга бүлеп чыгалар. Бер генә партия дә аерым юллардан тупланмый, үзара берләшү һәм командирларга каршы тору булмасын, диптер инде, һәр командага Себер яки Ногай һәм Уса яки Казан юлындагы волость вәкилләрен сайлап «тутыралар». Поляк крестьяннарына каршы юнәлтелгән «экспедиция» (кыру-җәзалау операцияләрен мендәрдән дә йомшаграк итеп тасвирлау буенча алар азау тешен чыгарган) корпусын генерал-поручик А.И.Бибиков җитәкли (ул ике елдан соң Пугачев фетнәсен һәм анда төп көч булган татар-башкорт крестьяннарын канга батыру өчен дә башкомандующий булып озатылачак һәм шунда җан тәслим кылачак). Ә «башкорт корпусы» генерал-майор А.А.Урусов кул астына беркетелә. Һәр партия урыс офицерлары командалыгына бирелсә дә, «башкорт» яугирләре белән үз старшиналары җитәкчелек итә.

«Башкорт корпусы»ның баш старшинасы итеп бүгенге Башкортстанның Балтач районыннан чыккан Кулый Балтачев атлы мишәр яугирен билгелиләр. Һәр 300 яугирле команданың да аерым старшинасы пәйда була. Беренче партияне Уса юлындагы татарлар яшәгән Гәйнә волосте старшинасы Рахманкул Иртуганов җитәкли. Партия составына Казан юлындагы Бүләр олысыннан (бүгенге Актаныш, Минзәлә, Мөслим авыллары дип күз алдына китерегез) 110 га якын җәйдагы белән бергә старшина Имәнгол Кутлин да кушыла. Шушы ук команданы бүгенге Илеш районында урнашкан һәм старшинасы Балта Сәфәров булган Сеңрән волосте һәм шул ук Илеш җирләренә туры килгән Елан волостеннан (старшиналары Сәлим Әитов) 50 ләп ир, Татарстанның бүгенге Мөслим районы җирләрендә урнашкан Ирәкте волосте старшинасы Шәрип Киеков юллаган 100 гә якын яугир белән дә ныгыталар.

Икенче 300 кешелек партия Себер юлындагы Сарт волосте (ул бүгенге Кырмыскалы районы мәйданына туры килмиме икән?) старшинасы Үмәтәй Уразембәтов кулына бирелә. Аның кул астына Красноуфимск каласы белән чиктәш һәм бүгенге Мәчетле районында урнашкан Кущин волостеннан (ә ул атаклы Пугачев бригадиры Бәхтияр Канкаевны үстереп биргән Олы Ака, Урта Ака, Габдулла, Әзекәй, Богалыш, Кызылбай кебек татар-мишәр авылларын үз эченә ала) старшиналар Малай Әсәнов белән Яхья Яхшыев кул астында килгән җәйдакларны, Морзалар волостеннан нәкъ шундый ук татар-мишәрләрне җитәкләгән старшина Туманча Янбашкин, Казан юлының Елан волостеннан (бүгенге Илеш районы) старшина Сәлим Әитов һәм Дуванәй олысыннан (Чакмагыш, Кушнаренко) старшина Ихсан Баязитов яугирләрен өстиләр.

Өченче команданы Казан юлы старшинасы Миндекәй Габделгазизов җитәкли. Бу партиягә Йәнәй волосте (бүгенге Актаныш һәм Әгерҗе) старшиналары Шәрип Айдаров һәм Гали Ярмөхәммәтов, Байлар олысы (Минзәлә, Тукай, Актаныш) башлыклары Муса Хәсәнов белән Туйхуҗа Мәмәтов (Тукай районының Оргыды авылыннан) алып килгән йөзлекләр кертелә.

Дүртенче партияне Ногай юлының бүгенге Әлшәй һәм Дәүләкән районнарында урнашкан авылларыннан туплыйлар. Кара-Табын волосте старшинасы булып торган мишәр яугире Кәип Җыямбәтов команда башлыгы итеп билгеләнә. Шушы ук волостьта башкортларның старшинасы булып торган һәм үзен сатлыкҗан итеп танытКан Кыдрач Муллакаев, шушы ук Ногай юлында булып исәпләнгән Чүби-Мин олысы башлыгы Гайсә Якупов, бүгенге Актаныш районы җирләрендә урнашкан Гәрәй-Кыпчак олысы старшинасы Күчәдек Рахманкулов, Юрматы волосте (бүгенге Шаран һәм Туймазы) башлыклары Котлыхуҗа Сәфәргулов белән Юлдаш Кутлин, бик тиздән Ногай юлының баш старшинасына әверелячәк башкорт Галибай Морзагулов алда без атаган мишәр Кәип-яугир кул астына баса.

Бишенче партия, нигездә, Ногай юлындагы Катай һәм Тәмьян олысларыннан туплана. Команданы Катай волосте старшинасы Ишкенә Гаисов җитәкли. Ләкин бу команда да Юрматы (Туймазы) волосте старшинасы Сәйран Сәетов алып килгән татар җәйдаклары белән ныгытыла. Алтынчы партия – Себер юлындагы 115 йортлы Шайтан-Көзәй волосте старшинасы Юлай Азналин – Салаватның әтисе кулына бирелә. Ләкин бу командага да Ногай юлындагы Тәмьян волосте яугирләрен һәм Гәрәй-Кыпчак олысыннан (бүгенге Актаныш районы) Арсланбәк Макшыгулов алып килгән җәйдакларны кушып куялар.

Җиденче партияне Бүләр волосте (Актаныш, Мөслим, Минзәлә) старшинасы Муса Мөслимов җитәкли. Аңа Юрми (бүгенге Азнакай), Сарайлы-Мең (бүгенге Сарман), Гәрәй (Актаныш), Кыргыз (Актаныш һәм Илеш), Уран (бүгенге Тәтешле) волосте старшиналары Биккенә Яушев, Ишали Теләүмбәтов, Габдулла Әитов, Күчем Сөләев, Микәй Габдрахманов, Микәй Йосыпов, Атнагол Тимеров (атаклы Мутиннар нәселеннән), Зәет Абдуллин, Сабих Сарманов алып килгән җәйдаклар буйсына.

Сигезенче партия Себер юлындагы Кущин олысы (Бәхтияр Канкаев иле) башлыгы Исәкәй Садиров кулына бирелә. Ләкин аңа да Уса юлындагы Гәйнә олысыннан Туктамыш Ишбулатов алып килгән татарларны, Илеш Шарыев белән Таулыкай Чураков кул астында килгән Бөрҗән олысы башкортларын да кушып куялар.

Тугызынчы 300 кешелек командагы әлеге дә баягы Елан волосте (Илеш) старшинасы Зөбәер Йосыпов җитәкли. Аңа Казан юлындагы Елдәк, Гәрәй, Кыр-Елан, Каршин, Кыргыз, Нәдер олысларында (Илеш, Чакмагыш, Бүздәк, Актаныш, Әлмәт районнары) Баязит Килмәтов, Сабих Сарманов, Әхмәр Шәрипов, Аптыкай һәм Юлдаш Мәскәүовлар, Биккол Нурбакин, Зәет Абдуллин, Сөләйман Миңнегулов, Йосыф Нәдеров (атаклы Нәдер Урәзмәтовның улы) кебек старшиналар туплап юллаган татарлар буйсына.

(Дәвамы 6 нчы биттә).

ХӘТЕРЕ БАРНЫҢ ӘЙТЕРЕ БАР

Кеше өчен хәтер мөһим булган кебек, милләтләр яшәешендә дә ошбу сыйфат зур роль уйный. Асылда, һәр милләтне җитди эшләргә аның тарихи хәтере вә ата-бабалары рухы аша тәрбияләнгән югары милли аңы рухландыра. Бу тулысы белән татар милләтенә дә кагыла. Шәхси планда хәтер төшенчәсен, гадәттә, ике өлешкә бүлеп карыйлар: тарихи хәтер һәм нәсел хәтере. Беренчесе кешеләрдә тарихи дәреслек нигезендә тәрбияләнсә, икенчесе инде һәр кешедә, ата-бабалары рухы аша, шәхси нигездә формалаша, аның канына сеңеп, геннар дәрәҗәсендә (нәсел күзәнәкләре аша) буыннан-буынга күчә һәм шулай хәтер булып саклана. Шуны истә тотып, татарда борынгы чорлардан ук нәсел шәҗәрәләрен өйрәнү һәм җиде буын бабаңны яттан белү кебек таләпләр дә гадәткә кергән. Ә иблис токымы өчен хәтерле халык хәтәр санала. Шуңа күрә, Урталык җирләрендә бу токым кайчандыр геосәяси максатларда урнаштырган тоталитар режим да соңгы биш гасырда биредә яшәгән халыкларның, тарихи хәтерен генә түгел, нәсел хәтерен дә җуйдырту өчен нык тырышты. Беренчесе ялган тарих ярдәмендә эшләнсә, шәхесләрне нәсел хәтереннән яздыруда инде мәкерле вә явыз ысуллар да мулдан кулланылды. Чөнки, хәтере барның әйтере дә бар. Аеруча кискен чаралар, әлбәттә инде, бу җирләрдә элек күп гасырлар дәвамында көчле дәүләтләр токкан һәм Дала хуҗасы буларак хакимлек тә иткән татар милләтенә каршы күрелде һәм алар әле бүген дә дәвам итә.

Әйе, татарның үткәне турында чит илләрдә сакланган һәм эчтәлекләре һаман ачыла барган тарихи чыганак вә хезмәтләргә (әйтик, фарсы тарихчысы һәм дәүләт эшлеклесе Рәшид әд-Дин, француз язучысы, политолог һәм философ Шарль Луи де Монтескье, инглиз галиме Эдуард Паркер һ.б. авторлыгында) караганда, татар халкының чын тарихы гаять бай да, гыйбрәтле дә. Ә ул тарихта милләтнең бүгенге варислары өчен иң фаҗигале дата булып, мөгаен, 1552 елның 15 октябре – аның үз дәүләтчелеген югалткан көне саналадыр. Чөнки милләтнең тарихи хәтерен яңартуда ул аеруча зур әһәмияткә ия. Яңа чорда инде бу дата, 1552 елда Казанны Явыз Иван гаскәрләреннән саклап шәһит киткән ата-бабаларыбызны искә алу чарасы – татар халкының Хәтер көне буларак билгеләп үтелә. Сәяси чара буларак, татар җәмәгатьчелеге Казанда аны, 1989 елдан башлап, һәр елны үткәрә. Бу чорда ул, шәһитләр рухына Сөембикә манарасы янында дога кылып та, Казанның үзәк мәйданы вә урамнарын тутырып, митинг вә халык йөреше рәвешендә колачлы итеп тә үткәрелде. Ә инде Татарстан җитәкчелеге республикада 1992 елның 21 мартында халыкара хокук нормалары нигезендә үткәрелгән референдум нәтиҗәләреннән тайпыла һәм чигенә дә башлагач, Хәтер көнен киң итеп үткәрүгә каршы сәяси басым елдан-ел арта барды. Бу аның форматы вә үткәрү урыны үзгәрүенә генә түгел, халыкның төшенкелеккә бирелүенә һәм сүлпәнәюенә дә китерде.

Соңгы тапкыр Хәтер көне митинг форматында, хакимият рөхсәте белән, 2021 елның октябрендә Тинчурин скверында үткәрелгән иде. Ә аңа кадәр (2021 елның маенда) Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы Аксакаллар шурасы Хәтер көнен, мөселман ел исәбе һиҗри буенча, һәр шәүвәл аеның 13 нче көнендә уздыру турында карар кабул итте. Моны ул Казанның егылуы һиҗри буенча 13 нче шәүвәл көненә туры килүе белән аңлатты. Регламент буенча, Хәтер көне Аксакаллар шурасы утырышыннан башлана һәм анда көннең актуаль мәсьәләләре тикшерелә. Шуннан соң имамнар, Казан Кирмәненә җыелып, ханнар җирләнгән төрбә янында дога кыла. Анда, Казанны яклап шәһит киткәннәр белән беррәттән, башка сугышларда һәлак булганнар да искә алына. Мондый карар татар милли хәрәкәтендә шактый гына бәхәсләр дә тудырды. Анда аны Хәтер көнен киң җәмәгатьчелек катнашында үткәртмәскә һәм онытырырга тырышу ысулы буларак та кабул иттеләр. Әмма Аксакаллар шурасы рәисе А.Әюпов ул чакта бу чараны, ул октябрьдә уза торган Хәтер көненә алмаш түгел, дип аңлаткан иде. Ә татар зыялыларыннан бер төркем, Хәтер көнен рәсмиләштерү тәкъдиме белән, Татарстан президентына мөрәҗәгать тә юллады. Әмма ул җавапсыз калды.

Бер яктан, Хәтер көненең һиҗри буенча да болай үткәрелүе начар түгел дә кебек. Тик ул күчеп йөри. Быел, әйтик, аны 3 майда үткәрделәр. Күпләр бу хакта хәтта белми дә калды. Киләсе елда исә ул 22 апрельгә туры килә икән. Күрүебезчә, өстәмә кыенлыклар килеп чыга. Ә инде, гомумән алсак, абсолют кыйммәтләр системасына күчү зарурлыгын таныйбыз икән, вакыт та, материя яшәешенең объектив формасы буларак, абсолют кыйммәт булып чыга. Ә һиҗри ел исәбе мөселманнарга, Пәйгамбәребез вафатыннан соң 3 ел үткәч (635 елда), икенче хәлиф Гомәр ибн Әл-Хаттаб тарафыннан, сәяси максатларда кертелә. Димәк, бүген инде бу хакта да (ягъни бөтен кешелек дөньясы өчен дә уртак һәм кулланырга да уңайлы булган ел вә вакыт исәбенә күчү турында) уйланырга вакыт.

Фоат УРАЗАЙ.

Авыл – телне саклаучы

Казандагы «Адымнар» күптелле комплексында авыл укытучыларының «Авыл укытучылары белән данлыклы» I республика форумы узды. Форум үзара хезмәттәшлек итү һәм педагогик тәҗрибә алмашу, авыл укытучысының абруен күтәрү, укытуның һәм тәрбияләүнең яңа формаларын эзләүне стимуллаштыру максатында үткәрелде.

«Бүген форумга 500 кеше җыелды. Авылдамы, шәһәрдәме – кайда гына булмасын, ул укытучы булып кала. Форумда авыл җирлекләрендә булган проблемалар, җитәкчеләрнең җирле укытучыларга ярдәм итүе, авыл укытучыларының абруен күтәрү мәсьәләләре турында сөйләшәбез. Авыл укытучысы –тәрбия, югары белем алу, зыялылык ягыннан авылда үрнәк кеше», – диде Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин.

Министр Татарстанда 848 мәктәпнең авылда урнашканын, 86 мең баланың авыл мәктәпләрендә белем алуын искәртте. «Форумда күтәрелгән төп мәсьәләләрнең берсе – кадрларның алмашынып торуы. Мәктәпләрдә кадрлар җитми. Бүген Казан федераль университетында белем алып, туган авылына кайтып эшләүче укытучылар чыгыш ясады. Кадрлар белән менә шулай эшләргә кирәк дип, үрнәк китерәм», – диде ул.

Аның фикеренчә, авыл зур миссия үти. «Республикада мәктәпләрнең 60 проценты авыл җирендә урнашкан. Авыл – безне яшәтүче, ашатучы, тәрбияләүче, телне саклаучы һәм телгә булган мәхәббәтне үстереп, аңа яңадан дәрт бирүче. Элек авыл укытучыларына шундый зур игътибар булды. Замана үзгәргән саен укытучы гына үзгәрмичә кала алмый, чөнки дөнья үзгәрә», – ди министр.

Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева Педагог һәм остаз елы җәмгыятьнең укытучыларга мөнәсәбәтен үзгәртергә ярдәм итәр дип саный. «Мондый чаралар аша без җәмгыятьнең игътибарын укытучыларга юнәлтә алабыз. Минемчә, укытучы – ул һөнәр түгел, ә сәләт. Бу кешеләрнең исемен бөтен шәһәр белергә тиеш», – диде ул.

Татарстанда барлыгы 22 мең педагог һәм хезмәткәр исәпләнүе, шуның 11 меңе (ягъни 33 проценты) – авыл укытучылары булуы турында әйтелде. Быел республикада 11 мәктәп төзелә, 4 млрд сум акчага 31 мәктәпкә ремонт ясалачак, шуларның 2,6 млрд сумы – федераль бюджеттан бүленгән.

Форум барышында авыл мәктәпләре укытучылары арасында сораштыру үткәрелде, укытучылардан үзләрен борчыган 2 меңгә якын сорау килүе әйтелә. Сораштырылучыларның 33 проценты – мәгариф оешмаларында матди-техник шартлар, 15 процентын – кадрлар, 11 процентын – финанс, 9 процентын - мәктәпләрне саклау һәм аз комплектлылык, 6 процентын – укытучы статусы, 4 процентын – мотивлаштыручы мохит, инклюзия, 3 процентын – интернет кебек мәсьәләләр борчыган.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Еники әсәрләре – экранда

Әмирхан Еники хикәяләре нигезләнгән «823 нче километр» фильмы «Мир» кинотеатрында ябык режимда күрсәтелде. Әлегә премьера һәм прокат вакыты билгеле түгел.

«Бу премьера түгел. Фестивальләрне үтми торып без премьера ясамыйбыз. Бу фокус төркемгә ябык рәвештә күрсәтү. Бирегә фильмны төшерүгә катнашы булган һәм татар киносына битараф булмаган кешеләр җыелган», – диде фильмның продюсеры, «Татаркино» оешмасы директоры Миләүшә Айтуганова.

«823 нче километр» Әмирхан Еники әсәрләре мотивлары нигезендә режиссерлар Ирек Хафизов һәм Әмир Галиәскаров тарафыннан төшерелгән.

Фильмда Әмирхан Еникиның өч әсәре – «Кем җырлады?», «Матурлык» һәм «Бер генә сәгатькә» хикәяләре берләштерелгән. Валерея Байкиева тарафыннан рус телендә язылган киносценарийны Әмирхан Еники иҗатын өйрәнүче әдәбият галиме Гөлфия Гайнуллина язучы теленә якынлаштырып тәрҗемә иткән.

«Сценарийны тәрҗемә итүче буларак, кайбер өлешләрдә Әмирхан Еники әсәрләреннән шушы текстка туры килгән өлешләрне кертеп урнаштырдым һәм моны кирәк дип санадым», – диде Г.Гайнуллина.

Галимә кинода яшьләрнең катнашуын билгеләп үтте. «Ә.Еникидән башланган хезмәт юлыгыз югары үрләргә күтәреләчәк. Бер тапкыр Әмирхан Еники теленә кагылсагыз, сез аны онытмассыз», – диде ул.

Фильмны карарга Әмирхан Еникинең кызы Флера һәм туганнары да килгән иде. Ул фильмны төшерүчеләргә рәхмәтләрен җиткерде һәм кайбер җитешсезлекләр турында фикерләрен әйтеп үтте.

«Мин Ирек Хафизов өчен бик борчылдым. Ул беренче тапкыр кино төшерә. Кинода чынлык та, фальш та бик тиз күренә – алдашып булмый. Иң мөһиме – атмосфера бар. Минем дә әтием белән шундый ук конфликт булды. Ә инде фильмның үзенә килгәндә, әйтелеп бетмәгән урыннар, буш диалоглар бар», – диде Татарстан кинематографистлар берлеге рәисе Илдар Ягъфәров.

Ул фильмда катнашкан артистларга, аерым алганда, Илдар Хәйруллин белән Алсу Гайнуллинага рәхмәтләрен җиткерде, аларны фильмның бизәге дип атады.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

1 нче биттә – Казанда узган «Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы» шәҗәрә фестиваленең финалыннан күренешләр. Фото: rais.tatarstan.ru

Шәҗәрә бәйрәме гаиләне ныгыта

Казанда «Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы» шәҗәрә фестиваленең финалы узды. Республика этабы җиңүчеләрен Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов бүләкләде.

Фестиваль программасы милли һәм гаилә ризыклары күргәзмәсеннән һәм «Таныш булыгыз, минем гаиләм, минем нәселем!» гаилә командалары бәйгесеннән торган. Анда гаиләләр үз шәҗәрәләрен концерт номеры белән тәкъдим иткән һәм милли костюмнар күрсәткән.

Фестиваль муниципаль, зона һәм республика этапларына бүленгән. Быел зона этабында Казаннан Лозов-Ярцевлар, Саба районыннан Хантимеровлар, Ютазы районыннан Габдрахманов, Зәй районыннан Әхмәтҗановлар, Аксубай районыннан Андреевлар, Кайбыч районыннан Гарәфетдиновлар гаиләсе финалист булды.

Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында Рөстәм Миңнеханов командаларның талантлы, бердәмлеге һәм үз нәселе тарихына мәхәббәте белән таң калдыруын, гаилә мөнәсәбәтләренең үрнәк мисалын күрсәтүен, нәсел реликвияләре һәм риваятьләре белән сокландыруын әйтте. «Сезнең гаиләнең тарихы – сезнең өчен генә түгел, ә сезнең балаларыгыз, оныкларыгыз, аларның балалары өчен дә таяныч. Хәтерне саклау һәм аны киләсе буыннарга тапшыру мөһим. Еллар узган саен үткәннәр турында – ил, туган як, гаилә тарихы турында ешрак уйланабыз. Татарлар җиде буын ата-бабаны белергә тиеш, дип, элек-электән әйтеп килгән», – диде ул.

Татарстан Рәисе фикеренчә, шәҗәрә бер нәсел вәкилләрен санап кына чыкмый, ә бер-берсен алмаштырып торган бердәм агымның аерылгысыз өлеше итеп тоярга мөмкинлек бирә. «Бүген нәсел тарихын өйрәнү, шәҗәрәләр төзү популярлашу сөендерә. Шәҗәрә фестивале бишенче тапкыр уздырыла. Бу безгә нәселдәге гореф-гадәтләрне сакларга, үстерергә, гаилә бәйләнешләрен ныгытырга ярдәм итә, Татарстан һәм үз гаиләңнең тарихына кызыксындыру булдыра», – диде ул.

Биш ел эчендә бәйгенең барлык этапларында 45 районнан 700 гә якын гаилә катнашкан – бу 10 меңнән күбрәк кеше дигән сүз, диде республика җитәкчесе. «Бу саннар артында бик зур һәм четерекле эш тора. Барлык гаиләләр дә беренче урынга лаек. Бу бик яхшы үрнәк, чөнки гаилә кыйммәтләре илебезне сакларга ярдәм итә. Һәр гаилә – ул төбәк, республика, ил тарихы», – диде ул.

Бишенче фестивальдә беренче урынга Саба районыннан Хантимеровлар гаиләсе, икенче урынга Аксубайдан Андреевлар гаиләсе, өченче урынга Казаннан Лозов-Ярцевлар гаиләсе лаек булды.

Бәйгенең республика этабында җиңүчеләргә дипломнар һәм беренче урынга лаек булучыларга 150 мең, икенче урынга 130 мең, өченче урынга 100 мең сумлык сертификатлар тапшырдылар.

Узган ел шәҗәрә бәйрәме «Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы – Без тарихта эзлебез» шәҗәрә фестивале дип үзгәртелде. Фестивальнең биш еллыгы уңаеннан быел истәлек китабы чыгару планлаштырыла. Анда гаилә тарихлары, аларның гореф-гадәтләре, шәҗәрәләре керәчәк. Чыгышларның фотолары һәм видеолары QR-код ярдәмендә карап булачак.

Әдәби бүләкләрне кемнәр алачак?

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әдәби премия лауреатларын билгеләде. Остаханәләр һәм Әлмәт белән Чаллы бүлекчәләре аша тәкъдим ителгән кандидатлар яшерен тавыш бирү юлы белән сайланды.

Гаяз Исхакый исемендәге премиягә ике кандидатура тәкъдим ителеп, күпчелек тавыш белән Роза Туфитуллова җиңеп чыкты. Ул рус, төрек телләренә дә тәрҗемә ителгән «Язмыш җиле» романы һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен тәкъдим ителде. Һади Такташ исемендәге премия күпчелек тавыш белән Марат Кәбировка бирелә. Җамал Вәлиди исемендәге әдәби тәнкыйть премиясенә Төркиядә яшәүче татар галиме Чулпан Зариф лаек булды. Язучылар аның татар әдәбиятын пропагандалаудагы зур ролен билгеләп үттеләр.

Туфан Миңнуллин исемендәге премия бердәнбер намзәт булган Зөлфәт Хәкимгә тапшырылачак. Фатих Хөсни исемендәге премиягә, кабат тавыш бирелеп, язучы Рафис Корбан лаек булды. Абдулла Алиш исемендәге балалар әдәбияты премиясе шагыйрәләр Рәхимә Арсланова һәм Фирдәвес Әһлия арасында бүленә. Ике кат тавыш бирү уздырылып та, алар тигез тавыш җыйды.

«Татнефть» белән берлектә гамәлгә куелган Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиягә Татарстан Язучылар берлеге тәрҗемәче һәм шагыйрь Алия Кәримованы тәкъдим итә.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Галимне онытмыйлар

Истанбулдагы Ислам тарихы, сәнгате һәм мәдәниятен фәнни өйрәнү үзәге ИРСИКА тарафыннан татар-төрек дөньясының күренекле тарихчы галиме Надир Дәүләт искә алынды.

Җыенда Мәрмәрә университеты төрки дөнья тикшеренүләр институты галиме Мәһди Генҗәли, Йедитәпә университеты фән-әдәбият факультеты тарих кафедрасы җитәкчесе Әхмәт Ташагил, Мәрмәрә университеты фән-әдәбият факультеты тарих кафедрасы җитәкчесе Әхмәт Канлыдәрә һәм Надир Дәүләтнең хатыны, язучы Берил Дәүләтнең чыгышлары тыңланды.

Надир Дәүләтнең шәкерте, профессор Ә.Канлыдәрә остазының тормыш юлы әсәрләре һәм иҗтимагый эшчәнлеге белән таныштырды. Аның галимлек сыйфатларын бәяләп, студентны тыңлый белүен, аспирантының фәнни эзләнү нәтиҗәсендә ирешелгән яңалыкларына чын күңелдән сөенүен һәм аны үсендерә, илһамландыра алу сәләтенә ия булуы турында сөйләде. Ә.Канлыдәрә Н.Дәүләтнең «Хәзерге чор төрки дөнья» китабының энциклопедик үзенчәлеккә ия булуын белдерде. Профессор Әхмәт Ташагил Н.Дәүләтне дус җанлы, самими, тырыш, юмор көче күәтле кеше буларак искә алды, аны төрек дөньясын гына түгел, һәм Көнбатыш, һәм Көнчыгыш дөньясын яхшы белүче сирәк галим дип атады.

Искә алу җыенын алып баручы, ИРСИКА архивы хезмәткәре, Истанбул университеты тарих галиме, Надир Дәүләтнең шәкерте Айна Әскароглу Н.Дәүләтнең шәхси хатларындагы фикерләре турында сөйләде, туганнарын, якыннарын ихлас кайгыртуы, һәр форсатта ярдәм кулы сузуын ассызыклады. Н.Дәүләтнең һәр темага профессионал күзлектән каравын, аспирантына һәрвакыт юнәлеш бирүен, һич авырсынмыйча киңәшләре белән юл күрсәтүен искә алды.

Әлеге җыен кысаларында Надир Дәүләт тарафыннан язылган әсәрләр һәм китапханәсендәге китапларның күргәзмәсе тәкъдим ителде.

Рушания АЛТАЙ.

«Болгар җыены» көтә

21 май көнне Болгарда ислам динен рәсми кабул итүгә багышланган «Изге Болгар җыены» үткәреләчәк. Җыенда Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ядкәрләреннән күргәзмә оештырылачак.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин күргәзмә өчен Пәйгамбәрнең 10 ядкәре кайтачагын әйтте. «Андый күргәзмәләрнең бездә булганы юк иде», – диде Д.Натфуллин.

Бәйрәм чарасы 9:00 сәгатьтә концерт белән башланачак. 11:00дә рәсми ачылыш тантанасы, 12:00дә Җәмигъ мәчете янындагы мәйданда коллектив намаз уку оештырылачак. Уннан унбергә кадәр Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин кече манарада тәүбә итү догасын укыячак.

Җыен дәвамында Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгында күргәзмәләр, остаханәләр эшләячәк. Кунакларның мәдәни программа, Татарстан халык сәнгать кәсепләре осталарының эшләнмәләре күргәзмәсе, билбау көрәше буенча турнир карау мөмкинлеге булачак. Барлык теләүчеләр гарәп каллиграфиясендә язарга өйрәнү буенча остаханәдә катнаша ала. Һәр кеше 5- үз исемен гарәп телендә язарга өйрәнәчәк.

Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы директоры Рамил Җиһаншин кунаклар өчен барлык уңайлыклар тудырылачагын әйтте. «Кунакларга уңайлы булсын өчен, территориядә 130 волонтер ярдәм итәчәк. Шәкертләр Җәмигъ мәчете территориясендә торачак. Алар кунакларга яулыкны ничек дөрес бәйләргә һәм ничек дога кылырга кирәклеген өйрәтәчәкләр. Тәһарәтханәләрнең санын арттыру турында да уйлыйбыз».

Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов Болгарны татар мөселманнарының изге урыны булуын билгеләп үтте һәм чарада катнашырга чакырды: «Борынгы бабаларыбыз аңлы рәвештә 922 елда Изге Болгар җирендә ислам динен кабул итеп, мөселман булганлыкларын бөтен галәмгә күрсәттеләр. Шул чорда да, Казан ханлыгы, Советлар вакытында да халкыбыз һәрвакыт Изге Болгар урыны хәтерләде. Советлар чорында әби-бабаларыбыз хаҗ кылудан мәхрүм булдылар. Алар Болгар җиренә барып, дога кылдылар. Ул хаҗ кылу урыны да, кече хаҗ урыны да түгел, әмма ул халкыбызның изге урыны. Болгар җире диннең халыкта сакланып калуына сәбәпче булды».

Чарада Татарстан Республикасы җитәкчелеге, Россия Федерациясенең 72 субъектыннан XII Бөтенроссия дин әһелләре форумының 1100 гә якын делегаты, Россия Федерациясе, якын һәм ерак чит ил мөселманнары Диния идарәләре вәкилләре, илнең төрле почмакларыннан һәм мөселман дөньясыннан мөселман җәмгыятьләре вәкилләре, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» 2023 XIV Халыкара икътисади форумда делегатлары катнашачак.

● Tranio халыкара күчемсез милек брокеры тикшеренүеннән күренгәнчә, былтыр россиялеләр иң күп фатирны Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре һәм Грузиядә сатып алган: Төркиядә – барлыгы 2,64 миллиард долларлык 16 432 торак объекты; БГӘ буенча төгәл саннар юк, 15 меңнән артыграк фатир; Грузиядә 8 айда – барлыгы 1,6 миллиард долларлык 15164 объект (шул исәптән 13152 фатир); шулай ук Испаниядә – 1685 фатир; Таиландта – барлыгы 122 миллион долларлык 813 фатир. РФ гражданнары өчен күчемсез милек базарында тагын Греция, Франция, Кипр, Черногория һәм Италия дә бик популяр. Чагыштыру өчен: 2022 елда россиялеләр чит илдә күчемсез милек сатып алуга барлыгы 10 миллиард доллар чамасы – «Роскосмос»ка Россия хөкүмәте бүлгән өч еллык бюджеттан (ел саен 3 миллиард доллар чамасы) артыграк акча сарыф иткән.

● Россиядә соңгы биш елда космоска барлыгы 100 объект аварияләрсез җибәрелгән (СССРда бу кадәр аппарат 1,5 елда очыртыла торган булган). Шул ук вакыт эчендә Кытайда – 235, АКШта – 230 объект уңышлы очыртылган. Былтыр Россиядә космосны үстерүгә 224 миллиард сум, быел 251 миллиард сум (3 миллиард доллар чамасы) тәгаенләнгән, Кытайда исә 2023 елда 12 миллиард доллар бүленгән.

Югалган өметләр һәм чынбарлык

Татарстан Фәннәр академиясендә «Төбәк тарихы һәм татар төбәк тарихын өйрәнү: тарих һәм заман» дигән темага Бөтенроссия фәнни-гамәли, тарихи-туган якны өйрәнү конференциясе узды. Аны Бөтендөнья татар конгрессының төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты җитәкчесе, профессор Альберт Борһанов әзерләде һәм алып барды.



Бу көнне конференциядә тәкъдим ителгән китапларның берсе - «1917-1922 елларда Татарстан һәм Башкортстанның барлыкка килүе яктылыгында Көнбатыш Урал буе: өметләр һәм чынбарлык» дигән документлар һәм материаллар җыентыгы иде. Аны Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының фәнни хезмәткәре, Башкортстан татарларының төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыяте башкарма комитеты җитәкчесе Руслан Мәсәгутов тәкъдим итте. Басманың авторлары – Руслан Мәсәгутов һәм төбәк тарихын өйрәнүче Марат Ибрагимов. Хезмәттәге тарихи очеркларны һәм кереш өлешен Р.Мәсәгутов язса, документларны бергәләп туплаганнар.

Китап 100 ел элек булган күңелсез вакыйгаларны искә төшерә. Тәкъдим ителгән документлар 1920 елларда ТАССР һәм БАССР формалашуы турында сөйли. «Республикалар оештыру мәсьәләсе ныклап өйрәнелмәгән. Документларны бөртекләп күздән кичерә башлагач, теманың без уйлаганнан шактый катлаулы икәнлеге ачыкланды», – диде китап авторы. Җыентык белән танышканда да, ике республиканың чикләрен рәсмиләштерү, милли республикалар төзелү процессының гаять четерекле булуын, советларның автономияләргә карата каршылыклы сәясәт алып баруын, Урал-Идел буе төбәгендә төрле сәяси көчләрнең хакимият өчен көрәшен аңлый барасың.

Казанда пролетариат диктатурасы урнашканнан соң, татар зыялылары башта Идел-Урал штатын булдыру турында хыяллана, төрек автономиясе проектын да кире какмыйлар, зур милли автономия төзү юнәлешендә эшлиләр. Татар-Башкорт республикасы проекты авторлары Мирсәет Солтан-Галиев һәм Сәхибгәрәй Сәет-Галиевкә Мулланур Вахитов та булыша. Әүвәл Татар-Башкорт социалистик союздаш республикасын төзү проекты туа. Бу республиканы төзегән очракта, территорияләрнең милли состав буенча бүленеше мәсьәләләре үзеннән-үзе хәл ителер иде. «Әмма партиянең тоткан курсы бик тиз үзгәрә, бер автономия урынына зур булмаган, милли хәрәкәткә гаять зур территориягә берләшергә мөмкинлек бирми, икътисадый ресурслар алуга юл куймый торган вак республикалар булдырырга кирәк була. «Бу советлар алып барган сәясәтнең ачык чагылышы», – диде Р.Мәсәгутов.

Ул билгеләп үткәнчә, 1918 ел мәгълүматлары буенча Россия империясендә 3 миллион татар булган. Шуңа күрә татар халкының зур автономиядә бергә туплануы большевиклар хөкүмәтенең җитди баш авыртуына китерергә мөмкин, кечерәк республикалар төзү кулай булыр, дигән фикергә киленә. Моннан тыш милләтне таркату һәм автономия эчендәге бәхәсләр җирле җитәкчелекнең игътибарын большевиклар сәясәтендәге уңышсызлыклардан читкә юнәлдерәчәк. Нәтиҗәдә ике автономия төзү карар ителә. Моңа каршы чыгу мөмкин буламы соң? Китап авторы Р.Мәсәгутов Татар-Башкорт республикасы проектын тормышка ашыру тулысынча мөмкин булуын белдерә. Бу шул биләмәдә яшәгән халыкларның тигез хокуклылыгына китергән булыр иде. Әмма ике республиканың милли җитәкчеләре, сәсәтчеләре арасында каршылыклар килеп чыга, нәтиҗәдә бердәм республика төзү проектын яклап кала алмыйлар. Моңа күп төрле вакыйгалар да сәбәпче була. Әйтик, Әхмәтзәки Вәлиди полиция материалларында башта «куркыныч татар милләтчесе» буларак исәпләнә. Башкорт милли хәрәкәтен җитәкли башлаганчы, киң мәгълүматлы татар тарихчысы Ә.Вәлиди башкорт хәрәкәтен ник җитәкләргә алынган соң, дигән сорау да туа. Чөнки Татар милли хәрәкәтендә ул беренче сафта була алмаган. Аның башында Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Әхмәт Салихов торган. Ә.Вәлиди үзенең сәяси тәкәбберлеге аркасында татар милли хәрәкәтенә сыймаган. Шуңа күрә ул Башкорт милли хәрәкәтенә керә һәм үзенең амбицияләрен тулысынча тормышка ашыра. Нәтиҗәдә, 1922 елда, Уфа губернасын бетереп, җирле халыкның фикерен исәпкә алмыйча, бу җирләрне Башкорстан АССРга кушалар. Бу золымлык нигездә губерна биләмәләрендә яшәгән татар халкына кагыла. Тора-бара башкортлар Уфа, аннан алдарак Оренбург губернасына кергән бу җирләрне, димәк ки, аның халкын «тарихи Башкортстан» дип атый башлый. Шулай ялган мәгълүмат таратыла, аны бу хакта хәбәрдар булмаган халык чынбарлык итеп кабул итә башлый.

Китапта шулай ук язучы, шул елларда әһәмиятле сәяси роль уйнаган Галимҗан Ибраһимов шәхесенә зур игътибар бирелгән.

Гомумән алганда, ике ел дәвамында дәүләт архивларында утырып, катлаулы хәлләргә кагылышлы документларны, шул елларда чыккан газета материалларын, вакыйгаларда катнашкан кешеләрнең истәлекләрен, мемуарларын туплап һәм өйрәнеп, авторлар тарафыннан гаять зур эш башкарылган. Р.Мәсәгутов искәрткәнчә, китапта тәкъдим ителгән документларның күбесе беренче тапкыр дөньяга чыгарылган. Табылган документларның шактые иске татар телендә язылган булган, бу исә өстәмә мәшәкатьләр китереп чыгарган. Документларны башта рус теленә тәрҗемә иттергәннәр һәм шушы рәвешле фәнни әйләнешкә кертеп җибәргәннәр.

Китап җәмәгатьчелек тарафыннан зур яңгыраш тапкан, галимнәребез тарафыннан да уңай, җылы бәяләмәләр алган. Авторлар китап буенча эшләүне тагын да дәвам итмәкче. Алар Мәскәү архивларыннан документлар, шул еллардагы газеталар материалларын табып, 1918-1922 еллардагы катлаулы хәлләрне күзаллауны киңәйтергә исәпли.

Минзәлә районы төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыяте рәисе Нәкыйп Гафиятов басманың югары дәрәҗәдәге фәнни китап булуын искәртте. Конференция барышында Ульяновск өлкәсенең татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр советы әгъзасы, хәрби хезмәт ветераны Ринат Илкин «История села Аллагулово» («Атнагыл авылы тарихы») дигән китабын тәкъдим итте. Эшне авылны нигезләүчеләрне ачыклаудан башлаганнар. Атнагыл һәм Рахманкол беренче күчеп утыручылар булган, документлар нигезендә күп хакыйкать ачылган. Әлбәттә Р.Илкин китабын язып чыгу өчен гаять зур эзләнү эшләре алып барган. Әмма минзәләле Н.Гафиятов китапта дөрес карта бирелмәвенә игътибарны юнәлтте. «Анда болгар чорында кыпчаклар һәм башкортлар яшәгән, «Великая Башкирия» дип язылган һәм чиктә Моська дигән шәһәр бар. Ул – Мәскәү. Бу картаны ясаган кешеләр Татарстанныкы түгел. «башкорт» сүзе XV гасырга кадәр гомумән кулланылмаган», – дип ачыклап үтте ул. Табигый башкортларның исәбе гомумән 20-30 мең чамасы булган. Башкортстан халкының 95 проценты татарлар. Тарихи китапларда Пугачев восстаниесеннән соң табигый башкортлар калмавы турында язылган. Урта Азиядән төрле кабиләләрдән 100 мең атлы азиат килүе, аларның үзләрен башкортлар дип белдереп, җир алулары турында да мәгълүматлар бар икән. «Чын башкорт юк, ә үзләрен башкорт итеп санаучылар бар», – ди Н.Гафиятов. Ул шулай ук типтәрләрне бутауларын да искәртте. «Типтәрләр башкортларда булмаган. Алар бары тик татарларда, чирмеш, вотяк, чуашларда булган. Чирмеш, вотяк һәм чуашлар, төрле тирәлектә яшәп, гаҗәеп төрле диалектлар ясап бетергән. Әмма татар типтәрләре беркайчан да башка халыклар белән берләшеп яшәмәгән, алар аерым авыллар булып гомер иткән, ислам динен тоткан, татар телен саклаган», – ди төбәкне өйрәнүче.

48 ел Себердә яшәп, туган җиренә кайтып төпләнгән Альберт Дәминов Чистай районындагы Иске Роман авылы һәм Дәминовлар-Мөхетдиновлар нәселе турында «Ике нәсел – бер кан» дигән китабын тәкъдим итте. X-XIII гасыр башларында булачак Роман авылы янәшәсендә болгарлар шәһәре булган. Аңардан саклану ныгытмалары белән шәһәр калдыклары сакланып калган. Шәһәрнең ничек аталуы билгесез», – ди А.Дәминов. Ул үзе архив материалларында казына торгач, «Әйшә шәһәрчеге» исемен табып алган. Ул якынча 1236 елда монголлар тарафыннан җимерелгән. Халкы исә якын тирәдәге җирлекләргә урнаша. Бу хәлләр зиратлардагы каберләр белән дә дәлилләнә. Аның иң зурысы – Ромашкино инешенең югары агымында урнашкан «ташбилге» – «Ханнар зираты». Анда XIV гасыр эпиграфия истәлекләрен табарга мөмкин».

Гыйльми җыенда икътисад фәннәре докторы, Казан федераль университет профессоры, Татарстан фәннәр академиясенең вице-президенты Вадим Хоменко һәм тарих фәннәре докторы, академик, дөнья мәдәнияте институты (ЮНЕСКО) ректоры Энгель Таһиров һ.б. катнашты.

Сөембикә КАШАПОВА.

Атнаның сәяси мизгелләре

РОССИЯНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ КЕМГӘ БӘЙЛЕ?

9 май көнне Кызыл мәйданда, гадәттәгечә, Җиңү параде үткәрелде. Дөрес, быел анда һава параде булмады һәм бронетехника да җиңү символы булган Т-34 танкын колонна башына куюы белән генә чикләнде кебек. Аның каруы, парадта бу юлы 10 меңләп хәрби хезмәткәр, шул исәптән махсус хәрби операциягә (МХО) җәлеп ителгәннәр дә катнашуы, шулай ук 120 берәмлек хәрби техника үтүе мәгълүм булды. Җиңү парадында катнашучылар алдында ясаган чыгышында Россия Президенты В.Путин МХО сугышчыларының хезмәтен югары бәяләде, ватанга каршы чын сугыш башлап җибәрелүе турында белдерде, шулай ук: «Нет сейчас важнее дела, чем ваша боевая работа. На вас держится сегодня безопасность страны, от вас зависит будущее нашей государственности и народа», – дип тә өстәде.

Ә 14 майда Төркиядә президент вә парламент сайлаулары үтте. Президент сайлавында 4 кандидат катнашкан. Төп кандидатлар икәү: бүгенге Президент Рәҗәп Тайип Эрдоган һәм оппозиция лидеры, Республика халык партиясе башлыгы Кемаль Кылычдароглу. Соңгысы исә кандидат итеп 6 партияне берләштергән Милли альянс тарафыннан күрсәтелгән. Төркия законнары буенча, беренче турда ук җиңү өчен, кандидатлардан берсе 50 проценттан артык тавыш җыярга тиеш. Тик беренче тур нәтиҗәләре буенча, Эрдоган 49,35% тавыш җыя алган, ә Кылычдароглу исә 45% тавыш белән генә чикләнгән. Шуңа күрә Төркиянең Үзәк сайлау комиссиясе президент сайлавының икенче турын 28 майга билгеләгән. Ә тавыш бирүдә сайлаучыларның 88,92 проценты катнашкан.

Сәяси атна исә башка вакыйгаларга да бай булды. Украина президенты В.Зеленский узган атнада Европа илләренә (Италия, Алмания, Франция, Бөекбритания һ.б.) сәфәр кылды. Ул булган һәр ил Украинага нәрсә белән булса да ярдәм итәчәге турында белдерде. Әйтик, Алмания бу илгә 2,7 миллиард евро күләмендә хәрби ярдәм күрсәтәчәге турында белдерсә, Бөекбритания инде еракка очып һөҗүм итәргә сәләтле дроннар бирәчәге хакында да әйткән (узган атнада гына ул еракка оча торган Storm Shadow канатлы ракеталарын тапшырган иде). Украинага хәрби ярдәмнең 1,2 миллиард долларлык яңа пакетын АКШ та биргән. G7 илләре Россиягә каршы экспорт һәм энергетика санкцияләрен киңәйтергә җыенуларын белдергән. Кытай Тышкы эшләр министрлыгы махсус вәкиле Ли Хуэй, Украинада вәзгыятьне җайлау мәсьәләсен уртага салып сөйләшү ниятендә, Россия белән Украинага, шулай ук ЕС илләренә сәфәр кылган. Молдова парламенты рәисе исә үз иленең БДБ парламентара ассамблеясеннән чыгу процессын башлап җибәрәчәге турында белдергән. РФ парламенты Европада гадәти кораллы көчләр турында килешүне (ДОВСЕ) гамәлдән чыгарган. Тышкы эшләр министрлыгы моның сәбәбен әлеге адымның анда хәлне үзгәртмәве белән аңлаткан.

Фоат УРАЗАЙ.

Башкортстан тарихы – башкортныкы гына түгел!

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Унынчы партияне Ногай юлының Тәмьян волостеннан чыккан Качкын Самаров җитәкли. Аңа Бушмас-Кыпчак олысы старшинасы, Пугачев явы барышында «Башкорт гаскәренең башкомандующие» дәрәҗәсенә ирешәчәк Кинҗә Арсланов, Пугачев гаскәренә иң беренче булып кушылган Ямансарый Яппаров кул астындагы башкортлар, Казан юлындагы Шәмшәде һәм Кыпчак олысларыннан Ишбулды Мостаев белән Бүләк Гомәров, Кыр-Танып волостеннан шәхсән Кулый Балтачев алып килгән татар-мишәрләр буйсына.

Менә, 3000 сугышчының берникадәр өлешен ачыкладык. Күңеле сукыр булмаган адәм балалары ул 3000 яугирнең ким дигәндә 2000 гә якынының татар яки мишәр булуын җиңел аергандыр. Һәм команда башлыкларының да күпчелеге – татар. Ә башкорт мөтәгалимнәре барыбер «Польша походында башкорт гаскәре катнашкан», дип күкрәк суга бирә. Янә бер кабатлыйк: азатлык өчен көрәшүчеләх дусларны изү-кыру өчен оештырылган кан коюда катнашу – һич горурлык түгел (бу тагын бер аяныч вакыйга белән дә аваздаш сыман). Ләкин ни хәл итмәк кирәк? Патша хакимияте таләп иткәч, башларын түбән иеп, татары да, башкорты да барган. Беренче партия Уфа каласыннан 1771 елның 16 декабрендә чыгып киткән булса, соңгы команда 1772 елның 4 гыйнварында кузгалган. Җәй башында генерал Урусов канаты астында Вильно һәм Краков калалары янында фетнәче полякларның зур гаскәрен тар-мар итүдә катнашканнар. «Җиңүгә» ирешкәч, Хәрби коллегиянең 25 августтагы фәрманы буенча, 2000 җайдак Уфага кайтырга юл ала. 4 нче, 8 нче һәм 9 нчы командага тупланган җайдакларны (старшиналары: Әлшәйдән Кәип Җыямбәтов, бүгенге Олы Ака төбәгеннән Исәкәй Садиров, Казан юлындагы татар волостьларын җитәкләгән Зөбәер Йосыпов) – барлыгы 933 яугирне Польшада «тәртип саклау өчен» калдыралар, әмма алары да 1773 елның көзендә ашыгыч рәвештә Казанга кайтарыла. Бактың исә, Җаек буенда Петр Федорович атлы «патша» баш күтәргән икән, өч команданы да аңа каршы юнәләчәк җәзачы генерал-майор Ф.Ю.Фрейман корпусына кушып куялар. Әмма Оренбург янындагы беренче бәрелештә үк «башкорт» командаларының өчесе дә Пугачев ягына качып чыга. «Патша галиҗәнабләре» Пугачев Бирдә бистәсендә Петербург мисалында Хәрби коллегия дә оештырып җибәргән. Бер ел элек кенә поляк крестьяннарын изеп йөргән Кинҗә Арсланов белән Ямансарый Яппаров – аның әгъзалары, ә Кинҗә «башкортларның башкомандующие» булып та өлгергән. Польша походында унынчы партия башлыгы булып йөргән Качкын Самаров та монда, ул хәзер – полковник, Уфа төбәгендәге фетнәче башлыкларның берсе. Пугачев дүртенче партия башлыгы Кәип Җыямбәтовны да рәнҗетми. Үз теләге белән кушылган өчен аңа полковник дәрәҗәсе бирә, өстәвенә аны Бакалы белән Нагайбәк крепостен камалышта тотучы фетнәчеләр башлыгы итеп тә озата. 1774 елның февраль һәм март айларында карательләр тарафыннан тар-мар ителгәч, Кәип-полковник үз отряды белән Казаннан Оренбургка таба юнәлгән генерал М.Голицын корпусына каршы да сугышка керә, Уфа белән Оренбург арасындагы яуларда да катнаша.

Ләкин 1774 елның көз башында Пугачев гаскәренең тулысынча тар-мар ителүе турында хәбәр килеп ирешә. Гөнаһларны «юарга» ашыкмыйча булмый, Кәип-старшина да башка «түрәләр» белән бергә карательләр каршына гафу үтенеп килә. Польша походындагы тырышлыгын исәпкә алганнардыр, Кәипне җәзага тартмыйлар, хәтта кабат туган волостенда йорт-аймак старшинасы итеп тә калдыралар. Ни галәмәт, Кәип бабай әле 1796 елда да исән була, җанисәп документларына да теркәлә. Уллары да үзе шикелле үк елгыр һәм уҗәт булган, ахры. Хәлил белән Әюп исемле ике улы 1812 елгы Ватан сугышында катнаша. Хәлиле яуда һәлак була, ә Әюбе 2 нче «башкорт» полкы составында батырлык күрсәтеп, Изге Анна ордены белән бүләкләнә. Берничә елдан соң, артыннан йөреп, Әюп Кәипов подпоручик һәм дворян дәрәҗәләрен алуга ирешә. Аның артыннан ук Кәипнең өч улы – Гомәр, Госман һәм Локман да дворян булып таныла. Кәип туып-үскән Сипәш авылы озак еллар буе Кәип булып та йөри, ахыр чиктә Әлшәй районындагы Иске Сипәш булып кала. Кәип командасында күрше Чуракай авылыннан Аккүбәк Түләкәев, Кыпчак-Әскәр авылыннан Арслан Өметбаев белән Әмир Мортазин атлы татар яугирләре сугышып йөрүен дә искә алыйк.



Польша походында 6 нчы команда башлыгы булып йөргән Юлай Азналин да истә. Ул үзе генә түгел, улы Салават та Пугачев гаскәренә барып кушыла. Юлайга бирелгән җирләрне өч тиенгә сатып алып, анда завод төзеп куйган «калын кесәлеләргә» үч итеп, 1774 елда әлеге старшина Сим һәм Йөрүзән заводын ут төртеп яндыра. Шуның өчен аны һәм улы Салаватны шул ук Сим заводы җирендә 25әр камчы белән тотып яралар һәм маңгайларына кызган тимер белән «мөһер» салып, Балтыйк буендагы Роверик сөргененә озаталар. 1997 елда әүвәл Юлай, ә өч елдан соң Салават шунда вафат була. Гаҗәбе шул: Салаватны барча җиһан белә, ә яугир Кәипне ул туган Әлшәй районында да искә алучы юк... Тукай районының Оргыды авылында старшина булып торган, Польша походына яугирләр озаткан, ә Пугачев фетнәсе башлангач туган төбәгеннән олы отряд җыеп, полковник дәрәҗәсенә ирешкән Туйхуҗа Мәмәтовны да бүген беркем белми. Минзәләне айлар буе камалышта тотуда катнашкан, әмма бер яу барышында яраланып җәзачылар кулына әсирлеккә төшкән, соңыннан башкаларга дәһшәт бөркү өчен басуда корылган дар агачына асып үтерелгән Нәдер волосте старшинасы Габдулла Ягъфәровны да һичкем искә алмый... Өстәл өсте мул бит: урыс аракысы түр башында, тозлаган кыяр да бар, ә тарих ник кирәк?

Бөек Риза Фәхретдин хәзрәтләре бик тә белеп язган: «Хива ханлыгы кадәр җиргә, Рокфеллерларныкы белән янәшә куярдай байлыкка ирешсә дә, татар байлары үз тарихын булдыру өчен сыңар тиен акча да чыгарып бирми», нәкъ шуңадыр коллыктан котыла алмыйча, чит кубызга биюен дәвам итә...

ТОЙГЫН

Күз алдында яманлагыз, Мактагыз – үзе юкта!..

Тойгын (Риф Тойгынов, 1946–2014) – күренекле башкорт шагыйре, драматург, җәмәгать эшлеклесе. 1997–2009 елларда Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, 2012–2014 елларда – идарә рәисе. Россиянең һәм Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (2006, 1997), Сергей Чекмарёв, Фатих Кәрим исемендәге әдәби премияләр (1998, 2005) лауреаты.

ЯШӘСЕН!

Көнне каплар әче яшькә
Тулышмасын күз.
Яшәсен, дим, бәхет дигән
Биш хәрефле сүз.

Кемнән дә кем, ят кешедәй,
Яшермәсен йөз.
Яшәсен, дим, туган дигән
Биш хәрефле сүз.

Яшәештә дуслык белән
Һәрчак көчле без.
Яшәсен, дим, солых дигән
Биш хәрефле сүз.

Тирең тамган басуларда
Иген уңсын көз.
Яшәсен, дим, икмәк дигән
Биш хәрефле сүз.

Мәле җитеп, гашыйк булсаң,
Сагышына түз.
Яшәсен ярату дигән
Биш хәрефле сүз.

Дөнья – хозур, һәркемгә дә
Матурлыгы үз.
Яшәсен, дим, Ватан дигән
Биш хәрефле сүз.

...Һәркемнең дә үз өлеше
Яшәргә һәм эшләргә.
Биш хәрефле сүзләр генә
Телимен кешеләргә!

КӨНЛӘШМӘГЕЗ!

Каш җимереп яшәргә ни
Ким соң җирдә без кемнән?
«Анда – бар да, миндә – юк», – дип
Көнләшмәгез адәмнән!

Һәркемне дә өстен куя
Акыл һәм сабырлыгы.
Барның тия барлыгы, тик
Тими аның тарлыгы.

Шуны ихлас аңлар яшькә
Җиту кирәктер тизрәк.
Ул чакта бит йөз ерту да
Булыр иде лә әзрәк.

«Җир йотсын!» – дип ант итәмен,
Сөйләр сүзләрем хактыр.
Көнчеллектә безне узып,
Алга чыгучы юктыр.

Нигә шулай?
Көнчеләргә
Каргышым булыр телдә.
Башкортымның җанын кыйган
Азмы яу купкан илдә?!

Шул яуларда батырлары
Башын салганга күбрәк,
Хәзер сөмсез, көнчеләре
Арткан бит бездә бигрәк.

Җаным әрнеп әйтәм инде,
Күңелем түгел бозык.
Шигыремне укыганнар
Уйлансын иде азак,
Уйлансын иде азак...

САЛАВАТ КҮПЕРЕ

Йолдыз белән йолдыз чәкәшкәндәй,
Күкрәгәндә яшен тау аша,
Хыялында озын бала чакның
Гаҗәпмени мондый тамаша?

Хушларымны алып, төсле күпер
Балкыганда җирнең котыдай,
Әтиемә ул да күренгәндер
Үзе кичкән яуның утыдай.

Шул күпергә карап күп йөгердем, –
Керфегемдә чәчрәп эреде.
Яңгырдан соң миңа күк гөмбәзе
Ачылырга торган сер иде.

Алданганым булды: күпер диеп,
Аҗаганны күреп кайчакта.
Әниемә ул да күренгәндер
Мич эчендә янган учактай.

Яшеннәрдән куркып калмадым мин,
Өйнең почмагына сыенып.
Күреп үстем: балкыр күпер барда
Яшәрлекне нурга коенып.

«Күпер күреп, ник уфтана?» – димә,
Соравыңа сагыш кушылыр.
Еракларда калган бала чакны
Юксынуым, ахры, шушыдыр.

ОЯТ!

Каләм тоткан бөгъзеләргә
Багышлыйм бу шигырьне.
Сезнең икейөзлелек бит
Чыгырымнан чыгарды.

...Ни бетмәгән макташу ул
Күз алдында...
Юк чама.
Авызлардан төкрек түгел,
Тел йоттырыр бал тама.

Табасыз бит сүзләрнең дә
Ай-кояшка торышын.
(Янәсе, ул иҗат белән
Бизәп яши тормышын.)

Әй шигырем, шундыйларның
Намусларын, дим, уят!
Күккә чөеп макташудан
Бабич[1] алдында оят.

...Ни бетмәгән яманлау ул
Үзе юкта...
Түз генә...
Берни тормый әйләндерү
Мал-туар «бизәгенә».

Табасыз бит сүзләрнең дә
Җирәндерә торганын.
(Янәсе, ул аягына
Карап сузмый йөрганын.)

Әй шигырем, шундыйларның
Намусларын, дим, уят!
Җиргә таптап яманлаудан
Мостай[2] алдында оят.

«Икейөзле булмагыз!» – дип
Әйтәм әрнеп шул хакта:
Күз алдында яманлагыз,
Мактагыз – үзе юкта!

[1] Шәехзадә Бабич.
[2] Мостай Кәрим.

ЯҢА ЕЛГА АЯК БАСКАНДА

Яңа елга аяк баскан чакта
Җырсыз йөрәк бүген бар микән?
Күзне чагылдырып җиргә яуган
Әллә бәхет, әллә кар микән?

Бу ак бәхет җиргә явадыр ул,
Шул карларда – кояш чаткысы.
Моннан соң да ырыс-бәхет тулы
Көннәрнең, дим, килер яктысы.

Бу ак бәхет җиргә явадыр ул –
Чаткылары балкый кояшның.
Тыңлый белсәң, шушы сихри мәлдә
Ак моңнары сибелә ак кышның.

Керфегемдә эри яуган карлар –
Күз яшеме әллә җиһанның?
Яңа елда теләк: күңелләргә
Яктылыгы күчсен иманның.

Көндәлек бар ыгы-зыгылардан
Калды сыман күңел бушанып.
Яңа елга аяк басабыз без,
Имин килеренә ышанып.

СОҢЛАУЛАР ЮК ЧЫП-ЧЫН СӨЮГӘ

Син йөргән бу сукмак – туган ягым,
Көн ачыла...
Томан тарала...
Сөю сүзе сиңа әйтер идем
Ятмаса, дим, еллар арада.

Син йөргән бу сукмак – туган ягым,
Нурга чумган бүген җир-күгем.
Синең белән соңлап очрашуым
Үкенечкә түгел, юк, түгел.

Син йөргән бу сукмак – туган ягым,
Ничек түздем икән бер кайтмый?
Яратылмый яшәп булса да бит,
Ничек яшисең соң яратмый?!

Түзсә түзә икән, аһ, бу йөрәк
Сагышымнан янып-көюгә.
Хәзер шуны аңлар яшьтәмен мин:
Соңлаулар юк чып-чын сөюгә!

* * *

«Гел татулык булырмы соң?» –
Шул хакта еш уйларым.
Нишләп яхшы кешеләрдән
Тормый дөнья тулаем.

Тагын яхшы булыр өчен
Китәр иде тарткалаш.
Элеккечә кабатланыр
Йөз ертулар һәм талаш...

Юк, калганын юрамыйм да,
Түгел һич тә кылану.
Яхшы-яман хакында бу –
Үзалдыма уйлану.

Дөнья ничек булсын инде
Сөмсез, юха, куштансыз.
Шуңа аны яклаганнар
Яши алмый дошмансыз.

БЕЛӘБЕЗ БЕЗ...

Беләбез без нигә шушы җирнең
Әйләнгәнен кояш янынннан...
Бер-бер артлы нигә төн артыннан
Көннәр балкып туа яңадан.

Беләбез без нигә күк йөзендә
Ак юл сызып йолдыз атыла...
Яшен яшьнәп нигә яңгыр ява,
Сулар ташып, бозлар ватыла...

Беләбез без хәтта ай серләрен,
Беләбез без йола-гадәтне.
...Тик белмибез: иң беренче булып
Кем чыгарган уйлап гайбәтне?..

МӘХӘББӘТТӘН ОЛЫ БУЛЫП БУЛМЫЙ...

Бик күптәнге бер әкият төсле
Җаныбызны бирәү иткән мәл.
Ул әкият хәзер синекеме,
Минекеме – әмма миңа җәл.

Мәхәббәттән олы булып булмый,
Яшьлек яшьнәп кенә үтүчән,
Ә, гадәттә, нигә әкиятләр
Булалар соң яхшы бетүчән?

КАЙТУ

Җилләр белән узышыпмы,
Җилеп килә ялгыз болан.
Ә мин аны шатлыгымнан
Йөгереп барып тотмак булам.

Кайда инде куып җиту,
Туп-туп килә елтыр тояк.
Баскан гына эзләреннән
Тузып кала үлән, кыяк...

Күз дә алмый карап барам,
Онытылып бөтен дөньям.
Җилеп барган шул боланны
Куып җитәр гайрәт тоям.

Әнә болан килеп чыкты
Упкындагы кыя ташка.
Буыннары дер калтырап,
Карап торган була аска.

...Еллар аша Уралыма
Кайтып киләм атлап салмак.
Дулкынланам, кыя ташта
Басып торган болан сымак.

Башкортчадан
Ленар ШӘЕХ тәрҗемәләре.

● Айзирәк ире Якуб Акчура (уңда) һәм Әнкара татарлары белән: «Мөнҗия» әсәрендәге Мөнҗиянең кызы Айсылу Токомбаева, ТРТ телерадиокомпаниясенең Татар бүлеге җитәкчесе Сәгыйть Хәйри, «Иделия» татар ашлары рестораны хуҗабикәсе Лилия Сабир.

МӨҺАҖИРНЕҢ КҮҢЕЛЕ НЕЧКӘ...

Айзирәк Гәрәева–Акчура – Төркиянең Искешәһәрендә яшәп ятучы милләттәшебез, Актаныш районының Качкын авылында туып үскән кыз. Аның белән бергәләп «Шәһри Казан» газетасында эшләгән идек. Инде Айзирәкнең Искешәһәргә килен булып төшкәненә дә 6 ел булган. Аның белән бу язма Бөтендөнья Татар хатын-кызлары съездында күрешкәннән соң туды.

– Төркиягә киткәннән соң, синең язучылык хезмәтең тагын да яхшырак җимешләр китерә башлады, Айзирәк. Мөһаҗирләр тормышын сурәтләгән әсәрләрең белән әдәби бәйгеләрдә җиңү яулыйсың, журналларда әсәрләрең басылып тора. Уңдырышлы туфракка төштең, ахры...

– Төркиягә күчеп китүем көтмәгәндә булды. Ирем Якуб Акчура – Төркиягә күчеп киткән мөһаҗирләр гаиләсеннән. Аның әти-әнисе Корыһөек дигән татар авылыннан. Ул авылга йөз еллар элек нигез салынган. Якубның күптәннән мондагы мөһаҗир татарлар турында яздырасы килгән, язарлык кеше эзләгән. Аңа исә минем телефонны биргәннәр. Килеп тапкач, күңеленә дә кергәнмен, күрәсең. Мин язмыйча торалмыйм, язарга утырсам, төнне-көнне дә онытам. Ул мине ничек бар, шулай кабул итте. Эшләү, иҗат итү өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырды. Ирем татар җәмгыятенең эшендә катнаша. Ул белеме буенча инженер, зур бер заводта компьютер системалары буенча урынбасар булып эшләгән. Көчле компьютерчы, бухгалтерлык белеме дә бар. Шул ук вакытта бик иҗади, нечкә күңелле дә кеше ул. Язган әсәрләремне дә беренче итеп аңа укытам. Ул миңа Төркия татарлары белән элемтәгә керергә, геройларны табарга булыша. «Бирүзә йорт», «Агай», «Истанбул малае», «Мөнҗия», «Казан әулиясе» кебек әсәрләрем барысы да мөһаҗирлектәге милләттәшләребезнең язмышларын өйрәнү нәтиҗәсендә иҗат ителде. Аннан соң Якуб төрекчәдәге нинди китапны карарга, нинди чыганакны укырга телисең, шул ук минута эзләргә тотына һәм табып та бирә. Хәзер вакытны әрәм итәсе килми, күбрәк эшләп каласы килә. Язу эшенә яшьрәк вакытта тотынырга кирәк булган икән. Казанда Диния нәзарәтендәге вазыйфам хәбәр язу, чыгыш әзерләү кебек эштән гыйбарәт, ә үз иҗатыма вакыт калмый иде. Чит илдә исә үз телемдә иҗат итәргә бөтен мөмкинлекләр ачылды. Иртә таңнан торып Юдинодан өчәр сәгать буе автобуста эшкә киләсе юк, йокларга кайтып егыласы юк.

– Искешәһәр – элеккеге татар мөһаҗирләренең күпләп яшәгән урыны. Син татар мохитенә килеп эләктеңме?

– Кайнанам башта безне Истанбулда каршы алды, килешемә пәрәмәчләр пешереп көткән иде, урыны оҗмахта булсын. Туганнар җыелышкан иде. Мин үземне әйтерсең лә, чит илгә түгел, күрше авылга барып төшкәндәй хис иттем. Аннары туганнары белән авылга кайттык. Хәзер без яшәгән Искешәһәрдә татар җәмгыятенең ишекләре ачык. Аралашып торабыз, очрашулар даими уза. Монда бит татарларның җыелыр урыны бар: Татарстан хөкүмәте ачкан Татар музее эшли. Мондый җәмгыять Әнкарада да бар.

Төркиядәге мөһаҗир татарлар үзләре дә төрле: инкыйлабка кадәр үк чыгып киткән татарлар бар, алар күбесенчә Искешәһәр тирәсендә; инкыйлаб аркасында кузгалып, Кытайлар, Европа аша килгән татарлар бар. Искешәһәрдә барысы да бик бердәм. Сабантуйлары үткәрәләр. Әби-бабайлар шунда оныкларын җитәкләп килә, татар ризыклары, уеннары белән таныштыралар. Элек мин Сабантуйлары үткәреп йөрүгә тәнкыйтьчел караштa идем, хәзер фикерем үзгәрде. Аны мөһаҗир татарлар сагынып көтеп ала, ул аларга Казанга, ата-баба туфрагына кайткан кебек хис бирә... Истанбулда Сабан туе паркта уза, Искешәһәрнекен авылда оештыралар. Нәсел-нәсәпләре белән җыелышып, чәйләрен, ашларын төяп чыгалар.

– Хәзер Төркиядә мөһаҗир татарларның 5-6 буыны гомер кичерә. Ничек яши алар, татарлыкны саклап кала алганнармы?

– Без татарлар яшәгән барлык авылларда булдык: Икепынар, Татарлар көе, Бөгредәлек, Әфәнде күпере, Гөрсу... Авылларны чагыштыргач, күрәсең: төрек хатыннары бакча эше белән артык ватылмый, чирәм чәчә, бер-ике куак роза утыртып куя да, шуның белән тәмам. Ә бездәге татарларның бакчасына керсәң, йөз төрле чәчәк! Татарлык шундый вак-төякләрдә чагыла, шундый кыйпылчыклардан җыела. Казаннан киеп килгән күмеш беләзегемне апалар исләре китеп карады: безнең әнинең, әбинең дә шундый ядкәре бар иде, дип хискә бирелделәр. Читтә яшәгәннәрнең күңеле тагын да нечкәрә. Юк кына нәрсәләр дә кыйммәтле тоела. Шул кыйпылчыклар әсәрләремә дә керә. Элеккеге мөһаҗирләр кызларын татарга бирергә, уларын татар кызына өйләндерергә тырышкан. Хәзер килгән татарлар башкача, алар дөньяга нык ачык, читләр тәэсирен тиз сеңдерүчән. Аннары, татарга монда эреп бетәр өчен шартлар да уңай: дин бер, телләр дә якын... Татарлар Төркиядә югалып калмаган, күбесе үз эшләрен булдырган. Бик тырыш халык, бизнеслар ачып, нәселләрен эшле-ашлы итеп калдырганнар. Рух көче нык, алар туган җирләрендә дә көчле нәселләр булгандыр. Шәһәрләрдә җир бирелсә дә, татарлыкны саклау өчен яңа җирләр табып, авыллар булып утырганнар. Соңрак аларның оныклары шәһәрләргә күчә, анда үз эшләрен ача башлаган. Без белмәгән, өйрәнелмәгән әллә нихәтле милләттәшләребез бар Төркиядә. «Казан әулиясе» дигән әсәремдә шуларның берсе, мөһаҗирлектә танылып, әллә нихәтле шәкертләр тәрбияләгән мулла турында бәян иттем. Бу дин әһеле Төркиядә бик таныла, аның шәкертләре хәзер җитәкче урыннарда эшли.

– Андый шәхесләр турында мәгълүмат ничегрәк табыла?

– Шәхесләр турындагы мәгълүмат бөртекләп җыела. Шул чор матбугатыннан, китаплардан берәр җөмләләп чүплим. Өйрәнер нигез күп. Бер яктан, Төркиядәге мирасыбыз (Исхакый, Максудилар...), икенче яктан, архивлар тулы кул тимәгән чыганаклар... Мин госманлы телен белмим, гарәпчәдәге архивларны укый алмыйм. Ләкин күп кенә документлар хәзерге төрекчәгә күчерелгән, шуларны үзләштерәм. Элеккеге төрек газеталарының электрон вариантка күчерелгән төпләмәләре бар, аларны укыйм.

– Төркиядә эшләүче галимнәребез белән элемтәң бармы?

– Әйе, үзебезнең галимә кызларыбыз белән аралашырга тырышам. Әйтик, Истанбулдагы Мармара университетында Ләйсән Шаһин бар, милли чараларда еш катнаша, чыгышлар ясый. Бартон университетыннан Алсу Камалиева –югары дәрәҗәдәге фән эшлеклесе. Аның укучысы күптән түгел Мәдинә Маликова иҗаты буенча диссертация яклады. Ул язучының дистәдән артык романын өйрәнеп, тәрҗемә итеп чыккан. Алсу киң колач белән эшли, шәкертләрен дә шуңа өйрәтә.

– Мөһаҗирләр арасында иҗаты белән танылган кешеләр дә бардыр.

– Татарлар арасында киносериаллар төшерүче, анимация фильмнары ясаучы режиссерлар шактый. Өмәр Байкул – режиссер, сериаллар төшерә, аның Казанда татар яшьләре көннәрендә катнашканы бар. Искешәһәрдә шуларның тагын берсе – Мостафа Явыз Гөл яши. Мөһаҗирләрнең алтынчы буыны вәкиле, үзенең «Рәсемле фильм» дигән анимация студиясе бар. Бабалары 1890 елда күченгән булган.

● Истанбул татар яшьләре әниләре теккән милли киемнәрдә, 80 нче еллар.

● Корыһөектә бер гаиләдә. Диварда мөһаҗир әби-бабалары фотолары.

Татарча сөйләшми, әмма телне аңлый. Истанбулның Босфор университетында психология белемен үзләштергән. Кечкенәдән рәсем ясау, комикслар белән дә мавыккан. Беренче мультфильмын берүзе ясаган һәм TRT телеканалына тәкъдим иткән. Аннары шәхси студиясен оештырган. Аның зур хыялы – Ибн Фадланның Болгарга килүе хакында мультфильм төшерү. Болгар җирләрен кайтып күрәсе килә. Мөһаҗирләрнең уртак хыялы бу, тик моның өчен мөмкинлекләре юк.

– Нигә кайта алмыйлар?

– Беренчедән, андагы татарларның да барысы да байлар түгел, ә юл бәяләре кыйммәт. Икенчедән, кемдер оештырсын иде, дип теләүчеләр күп. Пандемия башланыр алдыннан җыелып, Казанга машиналар белән кайтырга уйлаган идек. Кайчандыр бабалары килгән юл бит... Казанга кайту, авылларына бару... Әби-бабаларының туфракларына дога кылу... Пандемия афәте башланды да олылар арасында кемнәрдер чирләп китте, үлүчеләр дә булды. Шушы сәяхәт гамәлгә ашыруны көтеп тора...

– Соңгы арада Төркиягә татар мөһаҗирләренең яңа агымы килде. Меңләгән милләттәшебез йә вакытлыча, йә төпләнеп яшәргә ниятли. Алар татарлыгын саклап кала алырмы? Төркиядә татар мәктәпләре ачу мөмкинлеге бармы?

– Төркиядә милли мәктәпләр ачу проблемасы юк, ул канун белән тыелмаган. Билгеле бер санда кеше җыелып гариза яза икән, аңа мәктәп тә, укытучы да бирәләр. Руслар рәхәтләнеп рус мәктәпләре ача анда. Ә татарлар балаларын төрек мәктәбенә бирә. Чөнки безнең милләт һәрчак прагматик холыклы. Чит илдә балалары тизрәк җайлашсын дип телиләр... Артыннан йөрүче булса, татар сыйныфын ачарга мөмкин. Элеккеге мөһаҗирләр «шәһәрдә калсак, югалабыз, балалар татар икәнлеген онытыр» дип, авыл булып яшәргә киткән бит, үз мохитләрен сакларга тырышканнар. Яңа килүчеләр исә күбрәк интернет аша аралаша, очрашулар да үткәрә. Аларга эшләргә, балаларын укытырга кирәк, шуңа күрә алар элеккечә авылларда яшәргә теләми. Ә мәктәп булдыру аларның үз кулларында. Бу юнәлештә аерым кешеләрнең шәхси тырышлыклары белән азмы-күпме эш бара дип беләм. Анталия белән Аланьяга меңнәрчә татар килде.

– Төрекләргә кияүгә чыгып, килен булып төшүче татар кызлары да шактый.

– Төркиядә татар кызларын сабыр булганнары өчен яраталар. Чыннан да, төрек хатыннары белән чагыштырганда, безнең татар кызлары тыныч, сабыр күренә. Төрек хатыны эшләмичә өйдә генә утырырга мөмкин, тик барыбер өйдә ул хуҗа. Иҗтимагый тормышта да үз сүзләрен әйтә алалар, каршы төшүче юк. Андагы законнар хатыннарны яклый. Төрекләр шуңа күрә Россия, шул исәптән татар кызларына өйләнергә тырыша. Безнең кызлар турында сабыр, «акча аз» дип тинтерәтми, диләр. Әйтик, төрек хатыны бүген миңа алтын йөзек кирәк, ди икән, ире шуны эзләп чыгып китә. Безнең кызлар алтын күреп үсмәгән, менталитетлары шуңа бәйле. Татарда байлык күрсәткече алтын түгел бит – кеше көнләшерлек йорт-җир, капка-койма, бакча... Татар хатыны үзен гаиләне тартып баруда җаваплы хис итә. Ә Төркиядә гаиләне кем туйдырырга тиеш? – Ир-ат. Кибеткә кем йөрергә тиеш? – Ир-ат. Кем акча табарга тиеш? – Ир-ат... Хатыннары кайвакыт үти алмаслык таләпләр куеп, ирләрен чыгырдан чыгара. Аларга чыдый алмыйча хатыннарын үтерүче кызу канлы төрекләр дә шактый. Төрек хатыннарына «азат хатын» тәрбиясе кергән, шул үзен сиздерә. Ә татар хатыннары күпкә сабыр...

– Казаннан янә нинди тәэсирләр белән китәсең?

– Бер танышның сүзе йөрәгемә тиде – үзенең туганы турында ул «киттеләр» дип сөйли, ә күршесенеке хакында «качтылар» ди... Һәр ике очракта да сүз мөһаҗирлеккә китү турында бара... Хәзер халыкның кайгы өчен капкалары ачып куелган халәт. Чарасызлык халәте... Ул капкаларны ябып куярга беркемнең көче җитми... Бу халәттә кешеләргә уйламыйча сүз әйтсәң, рәнҗетүең бар. Халык ул барысын да аңлый, тик үзен бөтереп алган агымнан аерылып чыгарга көче җитми. «Казан утлары»нда минем «Гаҗизлек» дигән хикәям чыккан иде. Анда Икенче бөтендөнья сугышы вакытында әсирлеккә төшеп, чит илдә калган татарларның язмышы сурәтләнә. Елый-елый яздым. Съездда яныма килеп, шушы әсәр өчен рәхмәт әйтүче ханымнар булды. Бу әсәр аларның бүгенге күңел халәтләренә аваздаш, күрәсең. Төркиядәге мөһаҗирләрнең хатирәләрен тыңлап, сорашып язылды бу әсәр. Аларның күңелен ачу, сөйләтү бик авыр – үз эчләренә йомылганнар, чөнки әти-бабалары да аларга артыгын сөйләмәгән, зыяны тияр дип курыккан. Инде ачылып китсәләр, бик күп кызыклы әйберләр сөйлиләр. Тик ерак хатирәләрне саклаган буын берәм-берәм китеп бара. Алар белән күпме мирас китә... Хатирәләре – халкыбызның тарихи чишмәсе бит...

Эльмира СИРАҖИ.

● Корыһөек авылында Коръән ашы.

Укытучыга хөрмәтне кайтару зарур

Татарстан Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча комиссия рәисе Марат Әхмәтов бала өчен җаваплылыкны укытучы һәм мәктәпкә генә йөкләделәр дип саный.

«Соңгы 10-20 ел эчендә бала тәртибе, белемне үзләштерү мәсьәләсендә җаваплылыкны балалар бакчасы һәм мәктәпкә йөкләделәр. Алар гаепле булып калды. Укытучылар бер сүз әйтә алмый: баланы эшкә җәлеп итәргә, аның тәртибенә канәгатьсезлек белдерергә ярамый. Җәмгыять бала өчен бары тик укытучы һәм мәктәп кенә җаваплы булырга тиеш дип саный», – диде ул «Авыл укытучылары белән данлыклы» I республика форумында.

Аның сүзләренчә, бу мәсьәләне хәл итү өчен һәр кешенең фикерен, мөнәсәбәтен үзгәртергә кирәк булачак, бу – ике яклы процесс. «Укытучы, шәхес буларак, үзен һәрьяклап үрнәк итеп куя белергә тиеш. Җәмгыять аны шундый дәрәҗәдә җаваплы урынга куйган икәнен аңлап эшләргә, шул ук вакытта дәүләт аның хезмәтен бәяли белергә тиеш», – диде ул.

«Ике яклы процесс арасындагы балансны җәмгыятьтә тәэмин итә алсак, дәүләт тарафыннан булган мөнәсәбәт тә үзгәрер. Республикада мәгарифкә мөнәсәбәт өстенлекле. Республика бюджетының чыгымнары өлешендә өчтән берен мәгариф тәшкил итә. Ул – 130 млрд сум күләмендә. Минемчә, республика бүген мөмкин булганны эшли», – дип бәяләде республиканың вице-спикеры.

М. Әхмәтов авылны үзе бер тулы фәлсәфә дип атады. «Аны аңлау өчен, күз белән күреп, колак белән ишетү генә дә җитми. Анда яшәп карарга кирәк. Авыл – җәмгыятьнең рухи, әхлакый ныклыгын тәэмин итә торган үзәк. Авылда шушы ныклыкны, беренче чиратта, укытучылар булдыра», – диде Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары.

«Авылыбызда көннең икенче яртысында кибеткә икмәк кайткан вакытта бик күп чират җыела иде. Мине, укытучы малае дип, чиратсыз керттеләр. Ул чорда авыл кешесе алдында укытучы – иситкеч ак, пөхтә шәхес буларак кабул ителде. Мин укытучыга шундый мөнәсәбәт булган чорда үстем», – дип сөйләде ул.

Ул соңрак тормыш кыйммәтләре үзгәрүен, 1980 еллар ахырында башланган үзгәрешләрнең дә йогынты ясаганын әйтте: «Бүгенге көндә соңгы 30 ел эчендәге җәмгыятьтә булган процессларның нәтиҗәсеннән канәгать булмыйча, шуңа җавап эзлибез. Бу бик авыр җавап, аны дәүләт программалары белән дә хәл итеп булмый».

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

(Ахыры. Башы 17, 18 нче саннарда).

Әмирхан ЕНИКИ

Ана һәм Кыз

Ишектән чыгуга, ул чак кына апасы Хәлимә белән бәрелешмәде. Аның алдында җирдән калыккан шикелле, ашыгып килүдән кызарган, еш сулыш алудан күкрәкләре бер күтәрелеп, бер төшеп һәм бөтен тәненнән эссе бәреп торган апасы Хәлимә басып тора иде. Рәхилә, аның борчылулы сорау белән текәлгән күзләрен күргәч, кулыннан тотып, үзеннән калдырмыйча, тизрәк йорт алдына алып чыкты.

– Син нәрсә, берәр нәрсә ишетеп килдеңме?

– Маһирә хат бар диде.

– Йә?

– Син хатны уку белән бик үзгәргәнсең. Маһирәгә бер сүз әйтмичә өйгә кереп киткәнсең...

Рәхилә каты итеп иреннәрен кысты.

Хәлимә аның кулын кинәт кенә тартып куйды:

– Йә, әллә миннән дә яшерер идегезме?

– Акрын, синнән беркем дә яшерми.

– Нигә әйтмисең соң, хат кемнән?

– Хат... фронттан.

– Хәсәннәнме?

– Апа, сабыр бул... Хәсән үлгән...

Хәлимә, чак ишетерлек итеп:

– Үлгән? – диде, артка таба ава башлаган кебек булды, ләкин кинәт әче кычкырып, бөтен гәүдәсе белән алга, ишеккә таба ташланды:

– Әнием, әнием...

Рәхилә стена булып Хәлимәнең алдына басты, кулы белән каты итеп иңбашыннан тотып алды һәм көч белән җиргә таба иде.

– Тукта...

Бу минутта Рәхиләнең туры гәүдәсе тагы да үсә төшкәндәй булды. Менә ул күкрәген алга таба чыгарып басып тора, һәм моңарчы күренмәгән ниндидер бер көч, мәрхәмәтсез усаллык булып, аның йөзенә калка. Йомыла төшкән күзләрендә хәтәр бер коры чаткы кабына... Ләкин бу һич таныш булмаган кыргый көчнең кинәт шундый олы булып тууы апасын бик үк куркытмасын өчен (бу хәле аның үзенә дә шомлы булып тоела), ул тыелырга тырыша, тик тыелу аңа зур авырлык белән бирелә. Ачулы тавышында әчке калтырану сизелә, ул акрын сөйләргә тырыша.

– Нишлисең син? Бер кайгы җитмәгәнме сиңа? Берьюлы ике кайгы булсын дисеңме, аз гына уйлыйсыңмы син? Әйтүең белән үтерер идең бит. Белмисеңмени, ул ишектән күзләрен алмыйча аны көтә? Юк, әни моны белергә тиеш түгел. Ишетәсеңме?..

Хәлимә Рәхиләнең кискен кушуына чарасыз буйсынды. Ул хәлсезләнеп бөгелде, башын кулларына салды, ничектер кечерәеп калды... Һәм, тәмам ихтыярын югалткан бала шикелле, үксеп-үксеп еларга кереште.

– Апа, җитәр дим, ишетәсеңме, җитәр дим.

Хәлимә тыела алмый, елавы һаман көчәя бара. Рәхилә, борчылып, тирә-юненә карана, Читән буйлап күрше хатынның чишмәдән менеп килгәнен күрә, тиз генә Хәлимәне иңбашыннан тотып, селкеп ала:

– Тукта, дим. Әнә Сабира җиңги безгә таба килә. Яхшы түгел, тыела бел. Бала түгелсең бит.

Хәлимә тыелырга тырыша, йомарлаган кулын авызына куя, үксүен чыгармас өчен, бармакларын тешли... Алар икесе дә күрше хатынга аркалары белән борылып торалар. Тыныч, үзара сөйләшеп торалар кебек... һәм күрше хатын, бу ике туганның шушы минутта башларыннан нәрсә кичергәннәрен һич белмәстән, акрын гына алар яныннан үтеп китә. Рәхилә белән Хәлимәгә исә аның якынлашуы, узуы һәм ераклашуы бер гомер булып тоела.

Күрше хатын ераклашуга, Рәхилә йомшак кына дәшә:

– Апа, бәгырем, бар, кайт.

Хәлимә, суларга һава җитмәгәндәй, башын күтәреп:

– Хәсән туганым, Хәсән туганым, син кайда? – ди һәм янә үкси башлый.

Рәхилә Хәлимәнең чәчләреннән сыйпый:

– Апа, бәгырем, чыдыйк, бик авыр булса да чыдыйк. Бер безнең башка гына төшкән хәсрәт түгел бу... Апа, бәгырем, тыңла мине, бар кайт, балаларың белән бул, аларны сөй, тынычлан.

Һәм, култыгыннан алып, ашыкмыйча, сакланып кына капкага таба илтә. Хәлимә буйсынып атлый, хәлсез башын Рәхиләнең иңбашына сала, елавыннан туктый.

Рәхилә Хәлимәне тынычландырыр өчен уйлап, ләкин үз-үзенә әйткәндәй:

– Сугыш бу... – ди.

Хәлимәне капкадан озату белән Рәхилә өйгә, әнисе янына, ашыга... Өйдә тынлык. Өйдә җан иясе юк шикелле... Тик ачык тәрәзәләрнең ак пәрдәләре генә салмак җилфердәшә. Рәхилә сакланып кына агач карават янына килеп әнисенә карый. Ана йоклый. Ялгыз калган сабый бала шулай иркә, бөтен көчен һаваның назлап сөюеннән йоклап китүчән була... Әйе, авыру ана бала тынычлыгы белән йоклый. Саргаеп кипкән кечкенә йөзендә аның, – әйтерсең, уйларын, газапларын ниндидер сихерле кул сыпырып алган, – тыныч гамьсезлек.

Рәхилә, чебен кунып борчымасын өчен, акрын гына ак чыбылдыкны төшерә һәм аяк очы белән генә басып кире өйдән тышка чыга. Ишек алдының түренә узып, бакча рәшәткәсе буендагы яшел чирәмгә утыра.

Гаҗәп, Рәхилә үзендә елыйсы килү тоймый. Ә ул ялгыз калгач тыела алмам, елармын дип уйлаган иде. Бәлки, кайчан да булса бер елар, һичшиксез елар... Ә хәзер... Юк, бик тырышып караса да елый алмас иде. Яшьләре аның эчендә кибеп бетте һәм күңелендә тыныч бушлык, аз гына моңсу тыныч бушлык урнашып калды. Әмма моңсу бушлык төбендә, кайдадыр бик тирәндә, кагылырга хәтәр сызлавыклы бер төер ята. Рәхимсез ачу-нәфрәт төере бу! Һич шик юк ки, Рәхилә менә шушы минутта бәдбәхет дошманны үз кулы белән рәхәтләнеп буар иде, буар иде һәм... җиңеләеп калыр иде. Сугыш бит бу, үлем өчен түгел, тормыш өчен сугыш!

Хәсән!.. Әйе, Рәхилә аны карап үстергән иде. Янә үстермәсмени? Әгәр үз баласы булмаса, апаларының, сеңелләренең балаларын карап үстерер. Бер Хәсән урынына ун Хәсән үстерер!

Юк, бу минутта кайгысы бик зур булса да, Рәхилә елый алмый... Кулы тойган җир, аркасыннан сөйгән кояш, күзләренә караган чәчәкләр тыныч булырга кушалар, сүзсез, бары үзләренең шушында, аның әйләнәсендә булулары белән юаталар. Чыннан да, Рәхилә салкын-тыныч. Тик чигәсендә аның әле үзе күреп өлгермәгән ике бөртек чал чәче елтырый...

1942.

Киләчәкне кайгыртып...

С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры Роберт Шәймәрданов исемендәге Республикакүләм мәктәп театрлары фестиваленең йомгаклау турын уздырды. Биредә Минзәлә, Мөслим, Актаныш, Тукай, Сарман районнарыннан алты мәктәп театр коллективлары чыгыш ясады.

Роберт Шәйхел улы Шәймәрданов Минзәлә театры белән 28 ел җитәкчелек итте. Узган елның декабрь аенда, 60 яше туларга бер ай кала, ул бакый дөньяга күчте. Театр сәнгатенә мөкиббән шәхес иде ул, бөтен яшәеше театр булды. Фани дөньяда калдырып киткән эшләре бихисап: Минзәлә театрына нигез салучы Сабир Өметбаевның исемен кайтару, аны мәңгеләштерү, 15 елга сузылган бинаны төзекләндерү эшләрен тәмамлау һәм башка бик зур гамәлләр. Роберт Шәйхел улы балалар ярата иде. Артистларның, хезмәткәрләрнең – һәммәсенең балаларын исемләп белә, хәл-әхвәлләрен сораштыра, кайсы мәктәптә, нинди билгеләргә укыганы белән кызыксына. «Театр ул – иҗат организмы. Ул мәңге яшь булсын өчен, иҗат дәрте кайнап торсын өчен, театр коллективы һәрвакыт яшь көчләр белән тулыландырылырга, сәхнә осталары эстафетасын кабул итәрлек кадрлар әзерләнергә тиеш» – дия иде директор. Һәм шуңа да мәктәп театрлары фестиваленә Р.Шәймәрданов исемен бирү очраклы түгел. Рухи хәзинәләрне саклау һәм баету максатыннан 2023 ел Татарстанда «Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы» дип игълан ителде. Шул уңайдан, Минзәлә театры дирекциясе милли җанлы җитәкчесе исемен мәңгеләштерүне максат итеп, «Роберт Шәймәрданов исемендәге Республикакүләм мәктәп театрлары фестивале» уздыру турында карар кылды.

Фестиваль өч этаптан торды. 30 театр коллективыннан гариза кабул ителде. Бу зур чарада 1 меңнән артык укучы катнашты. Беренче турда ул районнарда барды, икенче турда сайлап алынган коллективларны театрдан мәртәбәле жюри карап, коллективлар белән якыннан танышты, үз киңәшләрен бирде.

Р.Шәймәрданов исемендәге Республикакүләм мәктәп театрлары фестивален Минзәлә районы хакимияте башлыгы Айдар Салахов һәм театр директоры Илнур Гайниев ачып җибәрде.

Фестивальдә беренче булып Р.Шәймәрдановның туган авылы – Мөслим районы Татар Шураны авылының төп гомуми белем бирү мәктәбе коллективы Галимҗан Гыйлмановның «Булат нигә яхшы укый?» әкият – тамашасын күрсәтте. Шулай ук беренче көнне Сарман районы Илексаз мәктәбенең театр коллективы Алсинә Галимованың «Әни исе» драмасын, Минзәлә районы Тауасты Байлар мәктәбе театр коллективы Галиәсгар Камалның «Бүләк өчен» комедиясен тамашачы хозурына тапшырды.

Фестивальнең икенче көнендә Актаныш районы Иске Кормаш мәктәбе театр коллективы Илгиз Зәйниевнең «Кәҗә, Сарык һәм башкалар» комедиясен, Тукай районы Калмия мәктәбе театр коллективы Нәби Дәүлинең «Җырлап узган җәй» музыкаль әкиятен, Минзәлә шәһәре гимназиясенең Рөстәм Муллин исемендәге «Сәяр» балалар театры Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» мелодрамасыннан өзек күрсәтте.

Барлык коллективларга да фестивальнең махсус кубогы, дипломы һәм истәлекле бүләге тапшырылды. Минзәлә театры дирекциясе «Р.Шәймәрданов исемендәге Республикакүләм мәктәп театрлары фестивале»н ел саен уздырырга, алга таба фестиваль географиясен тагын да киңәйтергә ниятли. Телебезне саклау, балаларда милли мирасыбызга хөрмәт тәрбияләү, татар театры сәнгатенә яшь кадрлар әзерләүгә юнәлдерелгән башлангычыбыз дәвамлы булыр, дип ышанабыз.

Нурсибә АДИЕВА,
театрның әдәби бүлеге мөдире.

Оренбург губернасында «башкорт» булып язылу һәрчак өстенлекле дәрәҗәгә китергән, иң мөһиме – әлеге катлам ирләренә имана мәйданы 40-60 дисәтинә күләмендә бүлеп бирелгән. Шуңа күрә Уфа өязе җирләрендә шундый ук зур мәйдандагы җир хуҗасына әйләнү нияте татарларны әлеге төбәккә күпләп күчеп утыруга этәргән.

Уфа өяземдә башкортлаштырылган авыллар

Сүзебезне Уфа өязендәге 8 нче «башкорт» кантонына караучы Муса авылы мисалыннан башлыйк. 1812 елда бирегә 7 кешелек гаиләгә ия указлы мулла Г.Мөхәммәтәминевне күчереп китерәләр. Моңа кадәр ул Стәрлетамак өязенең Бозаяз авылында гомер иткән була (сүз уңаеннан: 1774 елга кадәр бер үк вакытта мулла да, йөзбашы да булып торган, Пугачев явы барышында С.Юлаев белән бер үк минутта бригадир дәрәҗәсе белән олыланган һәм соңыннан аның белән бергә Рогервик сөргененә сөрелгән, шунда 1804 елда җан биргән аталы Канзафар Усаев яшәгән авыл бу). Анда мишәр старшинасы Ишмөхәммәтовка буйсынып яши. Ә Муса авылындагы халык саны 1816 елда 76 ир-ат һәм 75 хатын-кыз исәпләнә.

Гаҗәбе шул: мулла җанисәптә мишәр түгел, «башкорт» исемлегенә кертелә, гәрчә авылның 7 хуҗалыгында яшәүче 31 ир-ат һәм 44 хатын-кыз мишәр булып исәпләнә. Алар Уфа өязендәге 3 нче мишәр кантонында, Йорт старшинасы Хисаметдин Бәшировка буйсына. Авыл исеме төгәл күрсәтелмәсә дә, 80 хуҗалыкта гомер итүче янә 283 ир-ат һәм 274 хатын-кыз мишәр булып исәпләнә, алары Йорт старшинасы Абдулла Тәрәвутовка, йөзбашы Мозаффар Яхинга буйсына, Әбделхәсән Әбделҗәлилов һәм Әлделгаффар Әбделхәлилов атлы муллалар, тагын Гыйсмәтулла Хәбибуллин мөгаллимнәр булып исәпләнә. Без авылы күрсәтелмәгән мишәрләрне дә Муса авылы кешеләре дип саныйбыз.

Бүген Чишмә районына караучы Биккол авылында гомер итүче мишәр Габделнасыйр Сәетбатталов та 1816 елгы ревизия вакытында 3 нче мишәр кантонына буйсынган Тегермән авылына күчә һәм анда «башкорт» булып исәпкә алына. Биккол авылына Яңа Ябалаклы авылыннан 1813 елда күчеп утырган мишәрләр Бикташ Юлдашев, Котлыхуҗа Бикташев, Фәйзулла Ишбулдин, Күчәрбай Сөймәскулов та «башкорт» булып җанисәпкә кергән.

Тегермән авылы территориаль бүленеш буенча Бөре (Бирск) өязенә карый һәм ул 1850 елда да 3 нче мишәр кантонына буйсынган мишәр авылы дип телгә алынган. Андагы 59 хуҗалыкта 163 ир-ат белән 151 хатын-кыз яши. Шундый ук исемдәге икенче авылда 13 хуҗалыкта 34 ир-ат белән 37 хатын-кыз исәпкә алынган, 1816 елда алар 10 нчы «башкорт» кантоны башлыгы Дәүләтбай Йосыповка буйсынган. Ә Йосыпов үзе Бөре өязенең Хәлил авылыннан, аңа дворян дәрәҗәсе 1813 елда гына бирелгән, бер уңайдан кантон башлыгы да булып куйган...

Әсирлеккә төшкән кыргыз дәвамчысы булган Шөкербай Искәндәровны да 1815 елда Уфа өязендәге бүгенге Мәчетле районының Сабанак авылында «башкорт» дип теркәгәннәр. Оренбург өлкәсенең хәрби губернаторы кенәз Волконский фәрманы буенча шушы ук Сабанактан, шул ук вакытта Салҗегет авылына күчерелгән Ибнеәмин Бортаков, Бортак Габделвәһапов, Морсабай Бортаков, Каһарман Габделвәһапов, есаул Йосыф Албудин (Абдуллин-?) «башкортлар» булып исәпкә алынган. Хәтта, Йосыф Албудин «тәрбиягә» алган кыргыз Такый Буранов та «башкорт» итеп теркәлгән.



● VII ревизия язаларында «башкорт сословиесе» .

Югарыда телгә алынган Ибнеәмин Бортак (дөресе – Бөртектер, бәлки) улы Габделвәһапов (старшина ярдәмчесе, есаул), аның уллары Яһүдә белән Морзабай, янә Каһарман Габделвәһапов, Йосыф Албудин һәм «үз кешегә әверелгән» Такый Буранов 1834 елда да 8 нче «башкорт» кантоны старшинасы Исламгол Госман улы Кылычбаевка буйсынучы «башкортлар» булып җанисәпкә керә.

Сабанак авылына әйләнеп кайтсак, Ә.Әсфәндияров аның турында болай бәян итә: «1812 елда моннан 5 гаилә Салҗегет авылына күченә. Ә авыл Шөкербай Искәндәров, Иштүк Йортбагышев, Дәүләтбай Дәүләтшин (улы Сөярбай), Юмартбай, Мөхәммәтрәхим, Бунтыбай Мәртәбин, Такый Буранов атлы казахларны типтәр сыйфатында кабул итә». Без алдагы юлларда 1816 елда Шөкербай Искәндәровны гына «кыргыздан башкортка әйләндергәннәр», дип язган идек. Бактың исә, боларның барысы да акрын-акрын гына «башкортлашып» беткән икән.

Ревизия кәгазьләрендә мишәрләрне «башкорт» катламына күчереп кую очраклары башка авыллар мисалында да ачыклана. Мисалга, Акбаш авылындагы (бүген Кушнаренко районында) 4 кешелек Фәйзулла Биктимеров гаиләсе хәрби губернатор фәрманы буенча 1815 елда 8 нче «башкорт» кантонының «башкорт» катламы вәкилләренә әверелә. Нәкъ шул рәвешчә, 1811 елда мишәр булып исәпләнгән 4 кешелек Сәгыйть Сөләйманов гаиләсе дә, хәрби губернатор фәрманы буенча, 1815 елда 8 нче кантон «башкортлары»на әйләнгән. Нәтиҗәдә, авылдагы «башкортлар» саны элек Йорт старшинасы Габделгани Рәхимкулов кул астында булган 16 ир-ат һәм 16 хатын-кыз мишәрләр хисабына арттырылган.

Чынташ авылында (бүгенге Благовар районында) 1815 елда есаул Арсланбәк Черкесский тарафыннан ирекkә җибәрелгән Габделвәһап Тупеев гаиләсе дә, шул ук Оренбург хәрби губернаторы фәрманы буенча, «башкорт» катламына языла һәм авылдагы башкортлар саны 29 ир-ат һәм 34 хатын-кызга җитә. Моны ревизия кәгазьләрендә татарча язып Йорт старшинасы Шәмсетдин Сәгыйтов та раслый. Шушы ук Чынташта 1859 елда Г.Тупеевның улы Габделлатыйф Габделвәһаповның 12 кешелек гаиләсе дә «башкорт хуҗалыгы» булып исәпкә алына. Гәрчә авылның күпчелеген мишәрләр тәшкил итә.

Югарыда телгә алынган Арсланбәк Черкесский Агарды авылындагы үз крестьяны, 56 яшьлек Мокәй (Мокамай, Мөхәммәтҗан-?) Бозымовны һәм аның 19 яшьлек хатыны Гөлзәбыйганы да ирекkә җибәрә, 1816 елда алар хәрби губернатор фәрманы буенча «башкорт»ка әверелә. Бәләбәй өязенең Түрештамак авылында алпавыт Николай Тимашев тарафыннан ирекkә җибәрелгән Курманай Ибраһимов һәм аның гаиләсендәге 8 җан да, губернатор фәрманы белән, «башкорт» булып исәпләнә башлый.

Алпавыт Н.И.Тимашевның да (1755-1821) татар нәселеннән чыккан булуы турында әйтми калмыйк. Нәкъ менә шушы кеше 1812 елда Казанда «Кузы-Көрпәч» дастанын рус теленә тәрҗемә итеп бастыра. Аның хатыны Феодосья Петровна Бекович-Черкесская – татар Дәүләт морзаның оныкчыгы була.

Бәләбәй өязенең Яңа Купай авылыннан 1811 елда Бакай авылына (хәзер Кушнаренко районында) күчерелгән бертуган Хәилбәшир һәм Хәилназ Имангуловлар да мишәрдән «башкорт»ка әйләнә һәм үзе дә татар булган старшина Шәмсетдин Сәгыйтов кул астындагы 108 «башкорт» исәбенә йөри башлый. 1834 елда Бакай авылындагы «башкорт»лар саны 136 га җитә.

Шәрип авылындагы (Кушнаренко районында) мишәр ахуны Габделкадыйр Сөләйманов улы Габделфәттах та 1815 елда хәрби губернатор фәрманы буенча Угыз авылына күчерелә һәм «башкорт» булып языла. Угыз авылының үзендә җанисәп кәгазьләре биредә мишәр катламындагы 186 ир-ат белән 174 хатын-кыз гомер итүе һәм 34 кешенең «башкорт» катламына күчерелүе хакында бәян итә. Ә 1859 елда инде Угыз авылында 367 ир-ат белән 356 хатын-кызның барысы да «башкорт» булып исәпләнә башлый.

Шушы ук Кушнаренко районындагы Иске Кормаш авылының тарихы бик кызыклы. Ул вотчинниклар 1714 елда яшәргә керткән ясаклы татар Кормаш Байтимеров, Йосыф Сөләев һ.б. исемнәре (барлыгы 20 хуҗалык) белән бәйле. 1859 елда җанисәп үткәргән чакта җир мәйданы хакына 91 йортта яшәүче мишәрләр «башкорт» катламына язылган булып теркәлә. Әмма инде 2002 елгы җанисәптән соң власть ияләре «авыл халкының 54 проценты – башкорт, 44 проценты татар», дип шәрран яра.

1811 елда Байталлы авылында (Кушнаренко районы) нибары 2 хуҗалыкта бертуган Бурангуловлар фимилияле башкортлар гомер итә. Ләкин 1815 елда ук 3 нче мишәр кантонының Бикташ Әмирханов командасына буйсынган 13 хуҗалыктагы мишәрләр хәрби губернатор фәрманы буенча «башкорт» итеп үзгәртелә. Нәтиҗәдә 1834 елда авылда 132 «башкорт», 181 татар исәпләнә башлый. Соңгылары мишәр старшинасы Ибраһим Биктимеровка буйсына.

Ә татар дошманы Ә.Әсфәндияров үз китапларында «Байталлы авылына 1815 елда ике генә мишәр гаиләсе күчеп килгән, ә үзендә 8 башкорт, 192 мишәр, 8 типтәр яшәп яткан. 1834 елда авылда 143 башкорт, 20 типтәр, 196 мишәр яшәгән. Хәтта 1920 елда да башкортлар авылның яртысын тәшкил иткән», дип хәрәмләшүгә бара.

Ә менә бернинди рәсми оешмаларда да раслатмыйча, фәкать үзара гына төзелгән язма килешүдә Дуванәй волостендагы Иске Каратәкә авылы вотчиннигы Хазбулат Борчаков 1716 елда ук Байталлы җиренә кертелгән ясаклы татар типтәре Килмәмәт Уразгилдиннан: «ясак түләгәндә ел саен ике сусар тиресе тапшырып барырмын», – дигән вәгъдә беркетүгә ирешә. Соңыннан хәйләкәр татарлар асаба башкортлар белән берләттән сусар тиресе белән ясак түләп баруны нигез итеп, үзләрен дә «башкорт» катламына яздыруга һәм 40-60 дисәтинә җир эләктерүгә ирешәләр.

Таһир КӘРИМОВ,
Ш.Мәрҗани исемендәге
Тарих институты хезмәткәре.

Чыганаклар:

1. Асфандияров А.З. История сел и деревень Башкортостана и сопредельных территорий. Уфа, 2009.

2. Национальный архив Республики Башкортстан (НА РБ). Фонд И-138. Опись 2. Дело 165, 310, 363, 370, 371, 374-А, 456, 571, 644.

12. Пономарев В.К. Тимашевы и Оренбуржье. История рода Тимашевых. (электронный ресурс).URL.

13. Старокурмашево [электронный ресурс]. URL.


● 1953 ел.

● 2007 ел.

РӘССАМНЫҢ УҢ

Танылган рәссам, тыл ветераны Рушания Якупова 1928 елның 3 февралендә Оренбург өлкәсенең бик матур табигатьле Кызыл Мәчет авылында туган. Әтисе Мостафа – тимерчеләр нәселеннән. Тимерче дигәч, көнкүреш әйберләрен ясаучы күзаллана, әмма ул көмеш алкалар, йөзек, беләзекләр дә эшләгән. Әнисе Вафия – колхозчы. Ул еллардагы ачлык әлеге якларга да җиткән. Гаилә табада саранча кыздырып тук_ лана башлаган. Әтисе хәтта йомраннарны аулап кайткан. «Әни: «Әти йомраннар тотып кайта алса, аны шул көнне пешереп ашый идек, бик зур бәйрәм көне кебек була иде», дип искә ала иде» – диде Фәрит Харис улы әңгәмәбезне башлап.

Узган гасыр башында калган вакыйгаларны искә алганда, Фәрит әфәнде: «Әнием матурлыкны тоеп яшәгән гаиләдә үскән, әмма аның тормышында да авыр сынаулар чоры башланган. Әнием тормышы хакында китап язучы булмаячак, чөнки анда төрле маҗаралар юк. Дөрес, әтиебез Харис Габдрахман улының 7 китабы дөнья күрде, әмма аларның барысы да – рәссамлык сәнгате хакында», – дип ассызыклады.

Рушания дә чын ачлыкның ни икәнен күреп үсә. Ачлык белән бергә авыр чир, тиф та тарала. Тиф аркасында ул 5 яшьтән – этисез, 8 яшьтән әнисез кала. Тома ятим кызны абыйсы, рәссам Байназар Әлменов Казанда тәрбияли. Бөек Ватан сугышы башлангач, кыз 13-14 яшьлекләр бригадасы белән Яңа Бистәдә урнашкан снарядлар ясаучы заводта хезмәт куя. Эш сәгате 4 тә башланганга күрә, ул иптәш кызлары белән инде төнге өченче яртыда ук йокыдан тора, иртәнге салкында эшкә таба атлыйлар. Татар кызлары эшкә бер тапкыр да соңга калмый.

Аннары аны Казахстанда яшәүче апасы Сәбилә үз тәрбиясенә ала. Кыз Казалы тимер юл һөнәри училищесында укый. Уку йортын «бишле» билгеләренә генә тәмамлый. Аннары Дулёво сәнгать-һөнәр училищесына кереп, фарфор бизәүче һөнәренә өйрәнгәч, Казанга кайта.

1935 елдан башлап Татар китап нәшриятында сәнгать редакторы булып эшләгән абыйсы 1947 елда сәнгать редакциясе мөдире итеп тә билгеләнә. Аның дусты Харис Якупов та аның белән бергә эшли. Байназар Әлменов үзенең бик мөлаем сеңлесе Казанга килүе хакында дустына да әйтә һәм аларны таныштыра. Алар ел ярым дуслашып йөри. Ниһаять, Рушания Мостафа кызы һәм Харис Габдрахман улы 1950 елда гаилә кора. «Мин 1951 елда шушы гаиләдә өлкән бала булып дөньяга килгәнмен. Аннары, 1954 елда – энем Әнвәр, 1957 елда энем Айдар туды, – дип дәвам итте сүзен Фәрит Харис улы. – Әнием Казан сынлы сәнгать училищесына укырга кереп, аны 1953 елда тәмамлый. Хәзер совет чорын каһәрле вакыт дип сөйләүчеләр күбәйде. Ә мин алай димәс идем. Шушы совет власте, әйтик, минем әниемне, тома ятим кыз баланы укыткан бит! Ул бихисап картиналар ясады, башта – атказанган сәнгать эшлеклесе, аннары Татарстанның халык рәссамы исеменә иреште.

Әтиемнең «Рәсем – мәхәббәтем минем!» китабында шундый фикер дә язылган: «Хатын-кызларга күренекле рәссам булу ифрат читен, чөнки балалар үстерү, өй эшләрен карау аның өстендә. Шуңадыр, рәсем сәнгатендә алар бик аз. Татар хатын-кызларыннан иң беренче рәссам Хәдичә Акчурина. Ул Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Строганов исемендәге сынлы сәнгать училищесында укыган. Сәләтле рәссам булган, ләкин аның әсәрләре аз сакланган. Аннары Г.Рахманкулова һәм аннан яшьрәкләр, минем Рушания буыны рәссамнары инде...»

Әни әүвәл 25 еллап ТАССР Сынлы сәнгать фонды эшләрен алып барды. Сынлы сәнгать фонды бинасы соңрак төзелде. Шуңа күрә бар таблицаларны, төрле бизәү-сызуларны, плакатларны өйдә яза иде. Бу елларда ул чын иҗатта булмады. Аннары татар һәм рус әкиятләре буенча иллюстрацияләр ясады, кырык еллап шәһәр, республика, төбәк күргәзмәләрендә дә катнашты. Берничә шәхси күргәзмәсен Казанда һәм Болгарда уздырды. Ә иң мөһиме: әнием гел гаиләне кайгыртты, чөнки эти иртүк торып эшкә китә, остаханәсеннән кич кенә кайта иде. Ул иң күләмле картиналарын да иҗат дачаларында ясады. Ә андый эшләр икешәрөчәр ай иҗат итеlә. Кайберсе ярты елга да сузылды. Шуңа өй мәшәкатьләре күп очракта әни җаваплылыгында иде. Әйе, ире дә, хатыны да рәссам һөнәрендә булган гаиләләр күп. Әмма андый гаиләләрдә һәрчак үзара иҗади ярыш бара, аларның һәркайсы зур рәссам булырга тели. Ә менә безнең гаиләдә эти һәрьяклап бәхетле булды, әни аның өчен бар уңайлы шартны тудырды, аны җирдәге җәннәттә яшәтте дисәм дә ялгышмам. Әтиебез 1951-1975 елларда республика Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе булды, 1960-1968 елларда – РСФСР Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы, 1968-1987 елларда – шушы берлек идарәсе сәркатибе вазыйфаларын да үтәде, депутат та иде, иҗтимагый эшләре дә күп булды. Аңың әсәрләрен бихисап милләт вәкилләре күреп сокланды. Мәсәлән, 1983 елда Грузиядә РСФСР мәдәнияте көннәре үтте. Шул чакта анда эти белән әни бергә барды. Батумида этинең шәхси күргәзмәсе дә ачылды. Казанда Картиналар галереясы бинасында да этиемнең шәхси күргәзмәсе уңыш белән үтте, ул чакта этием галерея диварларына 800 картинасын элгән иде. Әйе, ул күбрәк иҗат итте, ә әни үз җырының бугазына басты, дияр идем. Ул үзен тыныч тотты, үз сәләте хакында искәртеп күкрәк какмады, этигә дә үпкәләмәде. Нәтиҗәдә, үзе дә бәхетле булды, этине дә бәхетле итте. Без дә рәссамлык һөнәренә укыдык, мин И.Е.Репин исемендәге дәүләт сынлы сәнгать институтын бетердем, Әнвәр В.И.Мухина исемендәге Югары сәнгать-сәнәгать училищесын тәмамлады. Айдар исә Казан дәүләт университетының физика факультетына кереп, радиофизика өлкәсе белгечлеген алды. Ни кызганыч, Әнвәр энем 44 яшендә вафат булды...


● «Габдрахман Якупов портреты».

●«Маһикамал Якупова портреты».

Әниебез бик матур да, ягымлы, көләч йөзле дә, кайгыртучан, игелекле һәм юмарт иде. Күп картиналарын, бер дә кызганмыйча, башкаларга бүләк итеп өләште. Әниемнең диварларга элеп куелган эшләрен күрүчеләр, аларга карагач, күңелләре күтәрелүен искәртте. Ә шәхси күргәзмәгә килүчеләр: «Менә табибләргә барганчы, бирегә килдек әле, Рушания Мостафа кызының әсәрләре – дару кебек тәэсир итә. Рушаниянең энергиясе, җан җылысы эшләренә кучкәне яхшы сизеләнә!» – дип, әниемне мактый иде.

Ул күп пейзажлар, натюрмортлар ясады, чәчәк бәйләмнәрен сурәтләүгә дә өстенлек бирде... Натюрморт өчен мөһим әй-

● «Хуш исле натюрморт».



● «Җир бүләкләре».

КАНАТЫ

● «Яңа самавыр».

● «Кыр чәчәкләре».

● «Сирень».

берләрне тезеп куйгач, башта аларга карап, сокланып утыра, аннары гына сурәтли башлый иде. Сирень чәчәкләрен аеруча ошатып ясады. Бакчабызда нинди генә чәчәкләр үсмәде! Авылда үскәнгә күрә, әни җирне ярата иде. Ә менә эти – ул бит Казанда туып үскән, ул җирдә казынырга өйрәнмәгән. Шуңа күрә бакчада чакта эти ни эшләсә дә, әллә ни яхшы итеп башкармады. Ә әни шау чәчәкле бакчабызга чыгып, шундагы чәчәкләрне мул итеп өзә, букет бәйләмнәре ясап куя һәм аларны икенче каттагы остаханәбезгә алып менеп, киндерләрдә сурәтли башлый иде. Шулай ук бакча җимешләрен, төрле яшелчәләрне дә еш ясады. Болар инде – 1970 еллардан башланган иҗат нәтиҗәләре. Коллекциясендә берничә портрет та бар. Әйтик, үз автопортретын, бабам Габдрахман һәм әбием Маһикамал Якуповлар портретларын ясады. Югары дәрәҗәдәге осталыкта, сыйфатлы итеп башкарылган хезмәтләр!

2008 елда «Хәзинә»дә ачылган күргәзмәсе «Татарстан сәнгатендә милли натюрморт» дип аталды. Галерея диварларына эленгән натюрмортларында татар көнкүрешендәге гадәти кирәк-ярак, фарфор чынаяклар, суы кайнап торган, балкып утыручы самавыр, сый-хөрмәт күрсәтү, милли кунакчыллык символлары – чәкчәк, өчпочмак, бал һ.б. барысы да җете төсләрдә, бәйрәмчә итеп тасвирланган. Әнием әсәрләре, чыннан да, якты оптимизм, чын милли рух белән сыйфатлана.

Аның күп кенә әсәрләре Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана, Төркия, Германия, Бөекбритания, Израиль, Франция, Япония, АКШ һ.б. дәүләтләрдәге шәхси тупланмаларны да бизи. Казанга килгән туристлар аның картиналарын бик еш сатып алды».

Фәрит әфәндедән нәсел дәвамчылары арасында тагын кемнәрнең рәсем сәнгате дөньясында кайнавын белешәм. «Гомумән, эти бар туганнарыбыз арасыннан 14 рәссамны барлаган иде... Балалардан Тимур, Алсу, Линда, Динә сәнгать мәктәпләренә йөрде. Айдарның кызы Линда Казан дәүләт инженерлык-төзелеш институтында укып, архитектор белемен алды. Бүген ул – талантлы дизайнер. Бер оныгыбыз, кызыбыз Алсуның улы Артур – дизайнер-модельер. Быел диплом эшен яклаячак. Тиздән ул да Мәскәүнең иң яхшы белгечләренең берсе булыр дип өмет итәбез, – дип ачыклады хөрмәт иясе һәм әңгәмәбезне болай дип дәвам итте: «Әнием поэзияне бик яратты. Күп китаплар укуы хакында да беләидек. Ә менә хәтере бик шәп булуын ул безгә 86 яшендә дә раслады. Беркөнне сәламәтлек хакындагы телевизион тапшыру карап утыра идек, алып баручы олыгайган өч ханымга үзләре белгән шигырьләрен сөйләргә кушты. Теге ханымнар 3-4 строфа сөйләде дә туктап калды, шигырь дәвамын хәтерләмиләр иде. Шулчак әни: «Кая әле мин дә хәтеремне тикшереп карыйм», – диде дә, Лермонтовның бик озын шигырен яттан сөйли башлады һәм... ахыргача ерып чыкты. Шаккаттым. Әнигә деменция дә кагылмады, ул җәфаланып, чирләп тә ятмады, 2017 елның декабрендә, 89 яшендә тын гына вафат булды». Шулай итеп, Фәрит Харис улының саф татарча сөйләвен тыңлагач, тагын бер сорау бирергә булдым: «Сез бер рус сүзе дә кулланмадыгыз. Ана телен яхшы белүегез әниегез тәрбиясе белән дә бәйле булып чыгадыр. Гәрчә сез дә совет власте елларында рус мәктәбен тәмамлагансыз бит». «Әйе, – дип җөпләде әңгәмәдәшем. – Мин рус мәктәбен тәмамладым, югары уку йортында да русча гына укыдык, аннары рус милләтле кыз белән гаилә кордым. Әмма мин үз ана телемне онытырга теләмәдем. Кызыбыз да кечкенә чакта гел татарча гына сөйләшеп үсте. Исемдә: әни әтинең «Рәсем – мәхәббәтем минем!» китабын нәшер итүне тизләтте, чөнки ул язылып беткәч тә, аны иң беренче булып әни укып чыкты, аны халык сөйләмендә кулланылган күп сүзләр белән баетты, редакцияләде. Кызыбыз Алсу Казан педагогика институтының чит телләр факультетын да, аннары Казан авиация институтын да тәмамлады. Әлбәттә, телләр белгән – илләр гизгән дигән матур әйтем дә бар. Телләр белү – ул бик күркәм! Ләкин без ана телен онытырга ярамавы хакында да белеп үстек. Татар телендә яхшы сөйләшүемдә әниебез тәрбиясе, аның өлеше зур булды!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

● Нажия Теркулова белән.

● Эмиль Җәләлетдинов белән.

● Әлфия Афзалова белән.

ТИРӘН ЕЛГА ТЫН АГАР

Татар халык көйләрен үзәкләрне өзәрлек итеп башкарса да, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, күренекле баянчы Фәнис Гыйльметдинов тыйнак кеше, әмма иҗат юлына күз салсаң, аның республикабызның музыкаль мәдәнияте өчен биниһая күп эшләр башкарганы яхшы күренә.

Ф.Гыйльметдинов идеаль ишетү сәләтенә ия, ди аның турында музыкант коллегалары. Аны баянда уйнарга өйрәтүче дә булмый. Әтисе Миңнуретдин – Актаныш районының Иске Байсар авылында танылган баянчы. Олы улы Фәнискә исә үз атасыннан калган, кабатланмас оста ясаган гармунны кулына тоттырырга кызгана. Әмма Фәнис тә үҗәт булып чыга, әтисе өйдә юк чакта, гармунны мунчага алып чыгып, кыряклап көй өйрәнә. Мәҗлесләрдә Миңнуретдин ага кәефсезләнеп кулыннан баянын төшергән вакытларда, чакырылган кунаклар, туган-тумача, көй сорап, улың уйный белмиме соң синең, дип ялвара икән. Уйныйм мин, дип батыраеп чәчрәп чыга шул чакларда Фәнис. Улының буш сүз сөйләргә яратмавын белеп, Миңнуретдин бу сүзләрен колагына киртләп куя һәм, вакыт узган саен, Фәниснең үз үзенә ышанычы арта гына барганын күреп, кадерле баянны аннан кызганмый башлый. Улы авылдагы концертларда ялтырап алгач һәм бигрәк тә район баянчылар бәйгесендә беренче урынны яулагач, үзенә кыйбат бәягә зур баян алып бирә. Мәктәпне тәмамлаганда, Ф.Гыйльметдинов бөтен районга танылган була инде. Шуңа күрә аны Пучы мәдәният йортына эшкә чакыралар. Аннары баянчы Мөслим районының Татар Бүләре авылы мәктәбендә җыр дәресләре алып бара. Кая эшләсә дә, һаман артистлар белән әвәрә килә. Әйтик, Минзәлә театры гастрольгә килгәч, Фәнисләрдә фатирда туктала, спектакльләрдән соң гармун тавышы белән моңланып утырганда, егетнең талантын бик тиз шәйләп алалар. Үзе сызылып киткән кара кашлы чибәр йөзле, мәһабәт буй-сынлы, үзе үзәкләрне өзәрлек итеп баянда уйный, хәтере шәп, беркем белмәгән көйләрне уйнап кына калмый, үзе үк җырлап та бирә. Өстәвенә, куе кашларын уйната-уйната, шигырь сөйли. Көлдерә торганнарын да, моңсуларын да үзенчә килештереп башкара. Әйдә, егет, безнең белән, сиңа укып торасы да юк, коеп куйган артист ич син, бик җиңел сәхнәдә уйнап китәчәксең, бөтен төп рольләр синеке булачак, теләсәң – Хәлилне, йә Булатны уйнарсың, чибәр кызлар көтүләре белән артыңнан калмый йөриячәк, дип кызыктыралар икән. Әмма Фәниснең үз планнары бар – Казан тарта аны, музыка училищесына укырга керергә исәп.

Иске Байсар, Пучы, Татар Бүләре халкы егылып тыңлагач та, Казан Фәнисне тыңлап һуштан язарга ашыкмый. Нота да таный белмәгән авыл баянчысын бөтен республикада дан тоткан сәнгать уку йортында колач җәеп каршыламыйлар. Кәефе нык кырылгын егет, документларны алырга килгәч, бәхетенә, баянчы Ильяс Шәриповны очрата. Ул исә өметле милли кадрны училищеның башлыгы Ильяс Әүхәдиевкә алып керә.

Әтисеннән курыкмаган егет, Казан профессорлары алдында да каушамый. Уку эшенә шундый итеп керешә ки, бер елга өч еллык программаны үзләштерә. Музыка мәктәпләре тәмамлап килгән шәһәр балаларын куып та җитә, узып та китә. Радиода языла, телевидениегә төшә башлый. Тиз арада танылып өлгерә. Шуннан талантлы баянчыны композитор Александр Ключарев ул вакытта филармония карамагындагы Татар җыр һәм бию ансамбленә эшкә чакыра. Бу – Байсар, Пучы сәхнәләре генә түгел, татар музыка мәдәниятенең йөзек кашы булган коллектив. Тормышта үз юлын күптән билгеләп куйган баянчы, Минзәлә артистларына кырт кискән кебек сөйләшми, җырчыларны җырлатырга, биючеләрне биетергә канатланып бара. Әмма Ключарев белдергән ышанычны акларга да кирәк бит әле. Ансамбльдә бераз эшләгәч, күренекле җырчыбыз Әлфия Авзалова Ф.Гыйльметдиновны үзенә баянчы итеп чакырган һәм алар байтак еллар бергә кулга-кул дус-тату, аңлашып иҗат иткән икән, Фәнис Миңнуретдин улы ансамбльдә үзен оста баянчы буларак раслаган, димәк. Мунчада әтисеннән качып көйләр өйрәнгән Байсар егете 1976 елда СССРның башкаласы Мәскәүдә танылган җырчыбыз Әлфия Авзалова белән аның беренче грампластинкасын яздыра. Биш елдан соң тагын берсен яздырып кайталар. Хәзер генә ул әзрәк гармун телләрен баскалый белүче – музыкант, борын тебендә көйләп йөрерлек кенә тавышы булганнар җырчы исәбендә йөри. Ә 1970-1980 елларда илнең асты өскә килеп, җиңел генә акча эшләп баерга теләгән халтурщиклар ишеймәгән әле, намус, вөҗдан төшенчәләре почетта, Мәскәүдә дә

теләсә кемне пластинкага яздырмыйлар. Ф.Гыйльметдинов үҗәтлеге һәм Аллаһ биргән таланты белән менә шундый югары үргә ирешә. Аңа кадәр Байсар егете бик зур әзерлек чоры үтә, әлбәттә. Җырчы Ә.Авзалова белән бөтен Союзны концертлар белән әйләнгәндә, ул баянчы буларак осталыгын чарлап кына калмый, андагы милләттәшләрнең татар сүзен, татар моңын ишетергә интизар булып яшәүләрен күреп, аларны күз карашларыннан аңларга, алар мәнфәгате белән яшәргә өйрәнә, күңеле милләтебезнең фаҗигале тарихы турында гамьле уйлар белән тагын да байый төшә. Офыклар киңәйгәч, күңелгә тирән уйлар иңгәч, баянда башкару да бүтәнчә, тагын да тирәнрәк, моңлырак була бара.

Баянчы Ф.Гыйльметдинов әнә шундый югары иҗат халәтендә Казан консерваториясенә читтән торып укырга килә. Кабул итү имтиханы ахырында бөтен Идел буенда данлыклы консерваториянең ректоры Нәҗип Җиһановның, үзе килеп, баянчының кулын кысуы, укуында уңышлар теләве гаҗәп түгел.

Без баянчыларны җырчы күләгәсендә иҗат итүче генә дип беләбез, тиешенчә кадерләмибез кебек. Юкса алар да, җырчы кебек үк, мәдәният мәгърифәтчеләре ләбаса! Әнә, Фәнис Гыйльметдиновны гына карагыз. Филармониянең музыкаль лекториендә музыка белгечләре Фатыйма Вәлиева, Йолдыз Исәнбәт, Зәйнәп Хәйруллина, Клара Таҗиева белән бергә ул республика мәдәният йортларын, предприятиеләрен йөреп чыга, татар халык музыкасы һәм аһәңсазларыбызның әсәрләрен генә башкарып калмый, Европа композиторларының музыкаларын да югары дәрәҗәдә уйный. Дус юлда сыналыр, диләр. Сәнгать белгечләре Ф.Гыйльметдиновны үз эшенә бирелгән шәхес, намуслы музыкант, мөкәммәл ишетү сәләтенә ия иҗат иясе, тугры дус, ялганны, ясалмалылыкны, дилетантлыкны кичерә белмәүче туры сүзле кеше буларак бәяли.

Шуңа өстәп, Ф.Гыйльметдиновның «Татарстан» телерадиокомпаниясендә төшерелгән ике шәхси программасы бар. Анда баянчы композиторларыбыз З.Хәбибуллин, Х.Вәлиуллин әсәрләрен һәм татар халык көйләрен үз эшкәртүендә башкара. Әйтергә кирәк, аһәңсазларыбыз Миңнуретдин улы Фәниснең эшкәртмәләрен бик ошаткан. Баянчының җырчылар Җ.Сәлахова, Н.Теркулова, Г.Ильясов, Р.Ильясов, З.Әхтәмова, З.Нурмөхәммәтов, В.Гыйззәтуллина, Х.Тимергалиева, М.Галиев һ.б. белән башкарган концертларның исәбе-саны юк. Һәр җырчының үз өслүбе, үз репертуары. Әмма Ф.Гыйльметдиновны берни куркытмый, ул теләсә нинди программаны җиңел үзләштерә, һәр җырчының күңеленә юлны таба белә. Эчми, тартмый, сүзендә торучан.

Филармониядә лекторий эше туктап торган арада исә ректор Рүзәл Юсупов баянчыны Казан педагогика институтына музыкаль тәрбия нигезләре кафедрасына эшкә чакыра. Кайчандыр клубта баянда уйнап йөргән Фәнис үзе авыл мәктәпләре өчен баянчылар һәм сәнгать җитәкчеләр әзерли. Бу максатта дәреслекләр дә яза. Аның «Баянда үзлегеңнән өйрәнү өчен кулланма» һәм «Баян өчен популяр көйләр» китапларының кыйммәте әйтеп бетергесез зур.

Җырчы Мөнирә ханым һәм баянчы Фәнис Гыйльметдиновларның бердәнбер кызлары Айгөл Казан сәнгать һәм мәдәният университетында биючегә укып, Санкт-Петербургта балетмейстер дипломы алып чыккач, үзе иҗат итеп, «Сөембикә» балетын үзе үк сәхнәгә куйган икән, бу да баянчы Фәнис Гыйльметдиновны чын милли җанлы иҗатчы һәм эти буларак тасвирлый. Шушы көннәрдә Фәнис агага 80 яшь тулды. Зур сәхнәләргә инде чыкмаса да, күңелендә һаман моң, кулында баян аның. Татар моңы исән чакта баянчы Ф.Гыйльметдиновның ихлас, тыйнак, эчкерсез күңеленнән чыккан тирән эшләре дә онытылмас.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Фотолар Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе архивыннан алынды.

Күптән түгел генә якташым Гөлчәчәк Садретдинованың «Тылсым көтә җаным» дип исемләнгән китабы Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Яшь кенә булуына карамастан 6 нчы җыентыгы инде. Учка сыярлык кына нәни басма минем кулымда. Җыентыкның исеме дә күңелне җәлеп итеп тора. Чөнки тылсым сүзе үк тылсым көченә ия. Гел шулай бит, һәрбер көннән, һәр очрашудан тылсым көтә безнең җаннар.

ТЫЛСЫМ КӨТӘ ҖАНЫМ

Әле хәзер дә, тылсым көткән күңелем, мөкиббән булып, тышлыкның рәсеменә төбәлгән. Менә бу сызыклар гомер җепләредер ул... Янып торган чаклар – кызыллары... Сары төсендәдер сагышлары... Һәм аклары! Алар күңелнең пакълегенә ишарәдер. Уртада – гомер шәме.

Шул яктылыктан үз дөньяма ут тергездем дә, әкрен генә китапны ачтым. «Бәхетле булырга хакым бар». Искиткеч ритм. Келтерәп поезда барган кебек. Башка шигырен дә бер «келтерәү» белән укыдым. Шигырьне генә түгел, табигать һәм яшәешне тоемлап яза автор.

Гөлчәчәкнең «Чистартасы иде» шигыренә әйләндем дә кайттым.

Терсәк якын, әмма тешләп булмый,
Хата арты хата кылына.
Биеп торгач һаман кубызына
Әйләнәбез шайтан колына...

Кыска гына шигырь. Ә уйлана башласаң, роман тирәнлеге бар.

Шагыйрә кеше язмышының көтелмәгән тибрәнешләрен үзенә генә хас алымнар белән укучыга җиткерергә, аны тормышның асылы, шәхеснең җирдә көндә тоткан урыны турында уйландырырга тырыша.

Бер ярлардан бер ярларга
Дулкыннар кага гына.
Тормыш китабым битләрен
Ачам да ябам гына.

Ил-көн казанында гомер итүче ханым:

Чиyләнгән уйларымны
Теземнәргә салып барлыйм, –
дип белгертә.

«Үзең булып кал» шигыренә бик рәхмәтле булдым. Ул мине кабат балачакка кайтарды. Гөлчәчәкнең табышы бу.

Шулчак түзми, кыя телгә килгән:
– Синең кебек ахмак сирәктер.
Биеклекнең күркe булыр өчен
Бөркет булып туу кирәктер.

Әлеге урында кыяга эндәшәсе килде:

– Зинһар өчен сүз әйтә күрмә инде каргаларга. Минем аларга карата аерым мөнәсәбәтем бар. Әгәр яраса, бер хатирәне язып үтимче?! Күршеләрнең бакча башында тупыллар үсә иде. Аның ботакларында һәрвакыт каргалар оялый. Ә мин бәбкә саклаганда аларны бик тә күзәтергә яратам. Әле мин олыларның тургай һәм сандугачларга гына мөкиббән икәнен белмим, табигатьнең кара киемле каргасын да Тәңребезнең гаҗәеп бер күренеше итеп кабул итәм.

«Минем каргалар турында язган кызыгызны күрәсем килә, – дигән язучы сатирик Фаил Шәфигуллин.

«Азнакай якын гына инде, чакыртабыз аны», – дигән тәвәккәл шагыйрь Зөлфәт. «Яшь ленинчы» редакциясе подписка алдында була торган тапшыру әзерли ул чакта.

Гөлчәчәк тә «Ялкын»журналы, «Яшь ленинчы» газеталары белән тыгыз элемтәдә торып, үзенең язмаларын , шигырьләрен балачактан ук аларга юллап



тора, иҗат чыныгуы ала. Хәзер исә үзенең балалары аңа иҗатына илһам бирә.

Әнием, ди, кара әле,
Каеннар алка таккан.
Ә миләшләр иңнәренә
Чуар яулыгын япкан.

Шигырьләр күктән алынса да, аларның нигезе җирдә. Сөйләмеңнең сүзләрендә, балаңның елмаюында, әниеңнең изге догаларында. Гөлчәчәкнең шигырьләрендә дә чагыла гаилә җылысы. Ятим балаларга кагылышлылары бигрәк тә үзәкне өзә. Чөнки үзе дә үксезләрне җылы кочагына алып җылыткан олы йөрәкле ана ич ул.

Рәнҗетсәләр балам,
калкан булып басам.
Ана арысландай ярсыйм,
янам, шашам...

Имтихан шигырендә болай дип яза шагыйрә:

Сорау булгач, җавабы да туа башымда:
Көтә безне уртак сынау
Аллаһ каршында.

Иншаллаһ, сынаулар аша динебез үргә менеп бара. Безнең Гөлчәчәгебез дә әкрен генә үз сукмагы буйлап алга атлый. Бүгенге көндә «Гөлстан» әдәби берләшмәсен җитәкли.

Рамазан аенда булдык, күпләребез ураза тотты. Бу – күңелләр берлеге, җаннар якынаю. Аллаһ Тәгалә дә бездән шуны көтә.

Вәсвәсәле уйлар коллыгыннан
Азат иткән безне уразадыр.
Киләчәккә изге гамәл аша
Атап сызган ул бер буразнадыр, –
дип яза Гөлчәчәк.

Бер хәдистә болай дип язылган: «Аллаһ Тәгаләгә иман китергәннән соң иң яхшысы – кешеләрнең бер-берсенә мәхәббәте». Һәр шигырь шушы миссиягә өлеш кертә икән, бу үз бурычын үтәгән шигърият дип санала.

Кайвакыт шундый халәт була: кемнеңдер шигырен укыйсың да, үз күңелеңнең дәрьясына кереп чумасың һәм, чиста-

рынып вә пакьләнеп, үз дөньяңа кайтасың. «Сәер дөнья», «Сагыну», «Сихри мизгел», «Үкенерлек булмыйк» – менә шундыйлардан.

«Бер чеметем җылы кирәк» дип яза автор.

Чынбарлыкны никтер һаман
Кабул итми минем йөрәк.
Коткарырга шул йөрәкне
Бер чеметем җылы кирәк.

Барыбызга да бер чеметем җылы кирәк. Кайвакыт бу – бер елмаю. Кайвакыт – бер моңлы җыр. Гөлчәчәкнең дә җырлары шактый. Татар эстрадасының танылган артистлары мәгънәле җыр сүзләре сорап, аңа еш мөрәҗәгать итә.

Кайчак белеп, кайчак белми кылып,
Ала күрмик берүк каргышлар.
Ялгышларны гына төзәтергә
Вакыт бирсә иде язмышлар, –
дип җырлый әнә бер җырында Рифат Зарипов.

Гөлчәчәк кебек барыбыз да еш кайта балачакка:

Балачагым авыз ерып
Ерганаклар буйлап чаба...

Ымсындыра татлы балачак. Ымсындыра әти-әни кочагы. Гөлчәчәк Әнәс кызы әтисеннән бик кечкенә чакта ятим калса да, бүген аны кочак җәеп каршы алыр газиз әнкәсе исән-сау! Ул Сарлы авылында гомер кичерә. Ул үстергән яран гөлләр, аяк очларына басып, кояшка таба үрелә. Ул пешергән тәмле ризыклар телеңне йотарлык. «Алма агачыннан ерак төшми», диләр, хактыр! Гөлчәчәк тә үҗәтләнә-үҗәтләнә иҗат кыйбласы буйлап алга омтыла.

Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА,
шагыйрә.

Борынгы гадәт – күркәм сәгадәт

Түбән Новгород өлкәсе Кочко-Пожар мәдәният йортында II округара «Шәпә туе» гөрләде. «Аулак өй»не хәтерләткән бу бәйрәмдә өч команда – хуҗалар, өлкәдәге Спас округының Татар Моклокасы һәм Пильна округы Сафаҗай белән Петрякс авылларының җыелма командалары катнашты. Бу төбәк татарлары бай тарихы, әби-бабайлардан килгән үзенчәлекле гореф-гадәтләре, йолалары, мәдәнияте белән аерыла. Алай гына да түгел, һәр татар авылының диярлек үзенә генә хас булган бәйрәмнәре, йолалары бар. Кочко-Пожар авылында да «Шәпә туе» дип аталган йоламы, бәйрәмме, кичәме диик инде – электән килгән. Бер карашка, ул шул ук «Аулак өй»не хәтерләтә, әмма исеме бик үзенчәлекле. Кайбер авылларда бу бәйрәмнең шулай ук үз исеме бар, мәсәлән, Сафаҗайда андый кич утырулар «Вечорка» дип аталган.

Шушы онытылып барган йолаларыбызга икенче сулыш өреп, аны торгызып, яшь буынга тапшыру өчен, өч ел элек, 2020 елның февраль аенда, Алсу Әхмәтбаева җитәкчелегендәге Кочко-Пожар балалар бакчасы коллективы «Шәпә туе» дип аталган бәйрәм уздырган иде. Анда, хуҗалардан гайре, Сафаҗай һәм Камка балалар бакчалары коллективлары катнашты. Һәр ел бу бәйрәмне уздырырга кирәк дигән фикергә килсәләр дә, коронавирус пандемиясе моңа комачаулады, ә менә быел, ниһаять, торгызырга булдылар.

Бәйрәм тарихы мәдәният йортының аккомпаниаторы Азат Җиһаншинның матур уйнавы белән башланды, аннары милли стильдә бизәлгән сәхнәгә алып баручылар – Алсу ханым үзе һәм дистә еллар авыл китапханәсе мөдире булып эшләгән Рамилә Мустафина чыгып, бу бәйрәмнең тарихы белән таныштырды, ә алар сөйләгәндә экранда 2020 елда узган «Шәпә туе»ннан күренешләр күрсәтелде. Ә инде олы яшьтәге әбекәйләр Сәкинә апа Зарипова белән Афифә апа Садековаларның видеога төшереп, экраннан күрсәтелгән хатирәләре бигрәк кызыклы һәм үзенчәлекле булды.

Чарада Сергач округы үзидарәсе вәкилләре дә булганлыктан, җирле хакимият хезмәткәре Олеся Мустафина борынгы бәйрәмнең мәгънәсенә кыскача гына русча аңлатма бирде.

Балалар бакчасы тәрбияләнүчеләренең матур җыр-биюләреннән соң, командаларны, тамашачыларны Сергач округы башлыгы урынбасары, мәгариф, спорт үсеше, яшьләр сәясәте идарәсе җитәкчесе Ирина Курасова, Кочко-Пожар территориаль бүлек җитәкчесе Рөстәм Абдуллин җылы сәламләде һәм чараның, иң беренче, яшь буынны тәрбияләүдә мөһимлеген билгеләп, катнашучыларга уңышлар теләделәр.

Наилә ҖИҺАНШИНА.

Төркия Исхакыйны юксына



Май башында Төркия башкаласы Әнкарада Идел-Урал милли бәйсезлек көрәшенең юлбашчысы, язучы һәм сәясәтче Гаяз Исхакыйны искә алу чарасы уздырылды. Җыелыш Исхакый тууының 145 еллыгына багышланды. Чараны Әнкарада яшәүче якташыбыз Роза Корбан оештырды. Анда Төркиядә яшәүче милләттәшләребез, төрле оешма һәм төрле милләт вәкилләре, студентлар катнашты.

Иң элек сүзне «Аяз-Таһир Төркестан Идел-Урал» вакыфының җитәкчесе, фән докторы Түлай Дуран алды. Ул вакыфның тарихы, Гаяз Исхакыйның кызы фәннәр докторы, профессор Сәгадәт Исхакый Чагатай (1907-1989) турында кызыклы мәгълүматлар бирде. Түлай ханым Исхакыйның кызы белән булган мөнәсәбәтләренә дә кагылып: «Ата-ана белән бала арасында җылылык, сөенеч булганлыгы хис ителә... Шул ук вакытта, озак еллар буенча очраша алмыйча, аерым яшәүләре сагыну сагышын тудырган һәм бу сагышны алар бары тик Исхакыйның гомеренең соңгы елларында гына бастыра алган», – диде. Түлай ханым Татарстанның язучы туып үскән Чистай районы Яуширмә авылындагы Исхакый музеена вакыф җибәргән Исхакыйның шәхси әйберләре турында да сүз әйтте. Шулай ук вакыф эшчәнлеге белән китаплар басылуын, төрле җыелышлар оештырылуын, фәнни тикшеренүчеләргә һәм студентларга стипендияләр бирелүен бәян итте.

Чараны язучы һәм тәрҗемәче, филолог Роза Корбан «Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗаты» дигән чыгышы белән дәвам итте. Ул: «Гаяз Исхакый – каберләре чит илләрдә калган, ә исемнәре бары тик 1980 елларда, үзгәреш җилләре исә башлаганнан соң, Садри Максуди Арсал, Йосыф Акчура кебек, соңыннан ватаннарына кире кайткан шәхесләрдән берсе», – дип кереш ясап, Исхакыйның тормышын, сәяси һәм иҗади эшчәнлеген аңлатып узды. Исхакыйның Төркиядә һәм Татарстанда басылган әсәрләре, истәлекләре, аның белән бәйләнешле басылган китаплар, уздырылган чаралар турында җентекле мәгълүмат бирде. Роза ханым язучының «Сөннәтче бабай» (1911), «Остазбикә» (1915) һәм «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902-1904) әсәрләрен танытты. «Язучы соңгы әсәрендә: «Әгәр милләт белән кызыксынмасак, үзебезне үстермәсәк, Казан татарлары ике йөз елдан соң инкыйраз булачак, ягъни юкка чыгачак», – дип безне кисәткән. Бүген без моны ап-ачык күрәбез», – дип, Роза Корбан Исхакыйның мирасын яшәтергә өндәде.

Аннары, Казахстаннан килеп, Әнкараның Хаҗи Бәйрәм Вәли университетында докторантурада укучы тикшеренүче, язучы Йелдос Токтарбай «Исхакый һәм казак зыялылары» темасына чыгыш ясады. Токтарбай бу көннең тарихи көн булуын, 1917 елның 1 маенда Мәскәүдә I Бөтенрәсәй мөселманнары корылтае ачылуын, Исхакыйның да бу корылтайның оештыручыларыннан берсе һәм утырыш башлыгы булуын, анда чыгыш ясаганын билгеләде. Ул үзенең эле бер атна элек кенә Мәскәүдә архив тикшеренүләре алып баруы, бу тикшеренүләр барышында Исхакыйның казах зыялылары белән югарыда әйтелгән корылтайда төшкән фотографияләрен табуы турында сөйләде. «Исхакый февраль революциясеннән соң Казахстанның Кызылъяр (хәзерге Петропавловск) шәһәренә китә. Анда ул «Маяк» исемендә Казахстанда беренче татар милли газетасын чыгара. Аның беренче номерларын без архивлардан таптык. Аларда Ленин һәм большевикларның ничек идарәне үз кулларына алуы, Идел-Урал һәм бөтен Төркестан зыялыларының ни өчен коммунистларның фикерләрен хупламавы турында язылган. Газеталарда бүген бөтен төрки халыкларны, төрек дөньясының берләштерүгә файдалы мәгълүматлар да бар», – диде ул. Исхакый белән Мустафа Чокай, Вәлид Хаттанаш кебек казах зыялылары арасындагы бәйләнешләр хакында бик күп кызыклы мәгълүмат җиткергән Й.Токтарбай Исхакыйның бары тик татарлар гына түгел, ә бөтен Идел-Урал төбәге, бөтен Төркестанның бәйсезлеге өчен бөек әһәмияткә ия шәхес булуына басым ясады. Токтарбай Исхакыйның барлык әсәрләрен диярлек төрмәдә һәм сөргендә язуын ассызыклап, Архангельскида сөргендә язылган «Тартышу» (1908) исемле драма әсәренең, казах милли газетасында басылганнан соң, казах зыялыларының аннан илһам алып, казахча беренче театр әсәрен язулары турында да бәян итте. Электән, Сталин чорына кадәр, Төрек дөньясының аерым милләтләргә аерылмавын, бу туфраклардагы халыкларның бер-берсенең телен яхшы аңлавын билгеләп, Токтарбай уртак телгә таянган киләчәгебез һәм Төрек Берлеге өчен, Гаяз Исхакый кебек, халкын сөйгән һәм аның өчен җаны-тәне белән хезмәт иткән барлык төрек шәхесләренең эшчәнлекләрен җентекләп танытырга һәм кулланырга кирәклеге хакында уй-фикерләрен ирештерде.

Чыгышлардан соң үзара фикер алышу һәм тәкъдимнәр ясалды. Төркия палаталар һәм биржалар берлеге университетының әдәбият факультетын тәмамлаган Әмрә Гөзтоклусу Исхакыйның «Өйгә таба» (1922) повесте һәм Әхмәтзәки Вәлиди белән булган мөнәсәбәтләре турында сорау бирде. Роза Корбан Исхакыйның I, II, III Бөтенроссия мөселманнары корылтайларында милли-мәдәни автономияне яклавын, Зәки Вәлидинең исә «туфракчылар» фракциясе әгъзасы буларак, территориаль автономияне яклавын әйтте һәм: «Бүгенге көн күзлегеннән караганда, минемчә, Зәки Вәлиди хаклы. Чөнки туфрак булмаса, Ватан булмый», – диде.

Тикшеренүче, язучы Мурат Гөзтоклусу үзе укыган Якын Көнчыгыш техник университетында эшләгән Зәки Вәлидинең улы икътисад фәннәре профессоры Субидәй Тоган һәм кызы тарих профессоры Исәнбикә Тоган хакындагы истәлекләре, Казахстанга сәяхәтеннән хатирәләр белән уртаклашты. Ул шулай ук Төркиядә яшәгән күренекле татарлар белән бәйләнешле мәгълүматлар бирде.

Малатья Инөнү университетының фән-әдәбият факультеты төрек теле һәм әдәбияты бүлегендә белем бирүче якташыбыз фәннәр докторы, профессор Рамилә Яруллина, сүз алып, Г.Исхакыйның төрекчәгә тәрҗемә ителгән әсәрләре, «Өйгә таба» повесте турында аңлатты. Рамилә ханым Исхакый әсәрләрендәге идеал каһарманнарының һәрвакыт хатын-кызлар булуына, милләтнең киләчәгенең укымышлы хатын-кызларның кулында булуына ышануына басым ясады.

Төрек дөньясы активисты, «Эпилепсия белән яшәү» оешмасы рәисе Әбру Өзтүрк Төрек дөньясында әсәрләрнең тәрҗемәсе, уртак тел булдыру, үз тарихыбызны үзебез язу кебек мәсьәләләргә кагылды.

Әнкарадагы Хаҗи Бәйрәм Вәли университетының әдәбият факультетында укучы Ләвәнт Булут татар теленең төрки дөньяда уртак тел вазыйфасын башкара алачагы хакында уйлануын белдерде. Ататөрек Төркия Җөмһүрияти төзегәндә иң элек Төрек тарихы җәмгыяте белән Төрек теле җәмгыятен коруын һәм аларның идарәсендә Төрек дөньясы вәкилләрен, шул исәптән татарларның булуы белән горурлануын искә төшерде.

Тәрҗемәче Лилия Сабир төрки дөньядагы бәйләнешларны ныгыту, төрки теле диалектларын үзләштерү өчен, үзара гаиләләрдә кунак булып, тормыш-көнкүреш белән танышу максат иткән туризмны оештырырга тәкъдим итте.

Катнашучылардан нәшриятче Зафәр Гөкҗан һәр халык өчен үз алфавиты булуның әһәмиятен билгеләп, хәзерге вакытта төрекләргә якын халыклар арасында бары тик Румыниядә яшәүче сәкәлләрнең үзебезнең руник алфавитны саклап килүләре, Төрек Берлегендә уртак алфавит куллану, мәдәният һәм ышаныч туризмнарын оештыру темаларына кагылды.

Лилия САБИР.
Әнкара.
(Фотосүрәтләр: Лилия Сабир, Әрҗан Билгин)

Милләтенә хыянәт итмәс әдип

(Миргазиян Юныс публицистикасына күзәтү)

Күренекле язучы-прозаик, публицист, сынчы Миргазиян Мөхәммәтзакир улы Юнысов (1927-2014) «Альбатрос язмышы» китабы өчен 2004 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе белән бүләкләнде. Ул китаптагы 17 язма бүген дә әһәмиятен җуймаган. Дөньяны гизгән дингезченең киң карашлы һәм тирән белемле булуы публицистик язмаларында документальлек, фактик төгәллек, тәнкыйди якын килү кебек сыйфатларында чагыла.

«Татар генералы татарча сөйләшә» дигән язма татар генераллары, атаклы хәрбиләре турында бәян итә. Аларның гыйбрәтле язмыш юллары милләтебезнең язмышын кабатлый, шуның белән дә хакимиятнең кимсетүле мөнәсәбәтен, гаделсез сәясәтен фаш итә. Татар халкының данлыклы уллары турында истәлекләр руслар тарафыннан юк ителә, алар урынына безгә рус геройлары каһарман итеп күрсәтелә. Әдип М.Юныс исә безнең каһарманнар истәлеген ничек тә булса саклап калуга, халык арасына таратуга омтыла. Ә язмада бирелгән шәхесләр исемнәре таң калдыра, аларны берничек тә искә алмый узып китәргә ярамый: Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Дәрдемәнд, Кандалый һәм, Миргазиян Юныс үзе дә белмәгән, күп-күп татар язучыларының китапларын укыган генерал Якуб Чанышев; сугышчан биремне үтәгәндә һавада һәлак булган Полбин; данлыклы космонавтиканың этисе, генерал-ас Савицкий; авиация генерал-майоры Таһир Сәйфетдинов; данлыклы Акчуралар нәселеннән, димәк татар милләте, төрки халыклар килечәге өчен көрәшкән Йосыф Акчураның токымдашы, ПВО гаскәрләренең зенит-ракета частьлары командующие булган генерал-полковник Рәсим Акчурин; Россиянең үсешенә зур өлеш керткән Ислямовлар нәселеннән адмирал Макаровның яраткан шәкерте, киңәшчесе, Төньяк Боз океанында югалган Седов экспедициясен эзләүне оештыручы Исхак Ибраһимович Ислямов, аның улы данлыклы Сикорскийның (дөнья авиациясенең атасы, Америка авиапромышленностена нигез салучы, Николай II шәхси пилоты) киңәшчесе һәм таянычы булган Ильяс Исхаков; СССР символыдай булган престиж-лайнер «Максим Горький»ның капитаны Марат Солтан улы Галимов; диңгез навигациясенең һәм диңгезчелек тәҗрибәсенең Сократы булып саналган Нариман Шәйхетдин улы Шәйхетдинов; 500 дән артык фәнни хезмәт авторы, Генераль штаб башлыгының беренче урынбасары, СССРның хәрби фәннәр оешмасының җитәкчесе, искиткеч акыллы, укымышлы генерал Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев; татарлыгыннан ваз кичкән, әмма шуңа бәгырь ите белән ачынып сыкранган күренекле рус шагыйре Михаил Львов; татар бизнесмены Наил Корбан улы Хәликъәев. Күргәнебезчә, бер генә язмада гына күпме таныш булмаган татар шәхесе, һәрберсе татарлыгы аркасында рус кешесеннән мыскыллаулы мөнәсәбәтен еш очраткан, әмма шуңа да карамастан, татар зыялыларына хас булган табигый тыйнаклык, мәһабәтлелек, тырышлык белән ил үсешенә өлеш керткән. («Очрашуга килгәннәрнең күбесе белән сөйләшеп чыктым. Миндә шундый тәэсир калды: алар арасында генераллыкны аванс төсендә, икеле-микеле алучылар юк. Киресенчә, планканы запас калдырып сикереп үтәргә туры килмәде микән әле аларга?

Күбесенең фәнни дәрәҗәләре бар: докторлар, кандидатлар. Язмышларын диңгезчелек һәм авиация белән бәйләүчеләр күп. Гаскәрнең бу төрләре исә пунктуальлек-төгәллектән тыш интеллектуаль егәр дә таләп итә. Йөзләреннән зыя-нур бөркелеп торган вице-адмирал Марс Искәндәров, Джон Кеннединың адъютантына охшаш контр-адмирал Әмир Бичурин һәм тагын күпләр, чыннан да, шундыйлардан.»)

Шулай ук татар хәрбиләре темасы «Су асты адмиралы», «Капитан үлеме» язмаларында да күтәрелә, диңгезче Габделәхәт Гомәр улы Габбасов һәм «Рокша» исемле лихтерның капитаны Хәнифә Шибаева язмышлары белән танышып китә алабыз. Анда да татар кешесенең тугрылыклы хезмәте тарих сәхифәләрендә пычратылып бирелә яки сызып атыла («Без озак еллар «никто не забыт, ничто не забыто» дип күз буяп йөрдек. Хәнифә апа Шибаева онытылган. Аны һәм аның белән һәлак булган экипаж әгъзаларын искә алучы, алар турында җылы сүз әйтеп, күз яше чыгаручы, бәлки, аларның якын туганнары арасында гына булгандыр.»)

«Аңларга тырышыйк, Борһанов» исемле язма – совет чоры диссиденты, профессор Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов; «Алдакчылыкка табынучылар» профессор, фән докторы Вил Мирзаянов язмышларына багышланган. Әлеге язмаларда шәхес фаҗигасе белән совет системасы һәм аны алыштырган хәзерге Россия системасы «явызлык империясе» буларак фаш ителә: татар галимнәренең казанышлары, тарихка объектив карашлары рус хакимияте тарафыннан аяк астына салып таптала («Озак еллар фәнгә гадел хезмәт итеп, чын галимлеккә ирешү «заслуга» түгел микәнни? «Заслуженный»лардан тыш фән өлкәсендә «незаслуженный» галимнәр дә эшлиләр микәнни соң?») Татар тарихына, гомумән, милләтенә карата субъектив гаделсезлек проблемасы әлеге очеркларында гына түгел, публицистның бөтен язмаларында кабыргасы белән куела. Шул ук «Конгресс» исемле очеркта да әдип Финляндиядә Лахти конгрессында катнашу, фин татарлары белән очрашу истәлекләрен язганда, Россиядән чыгып китәргә мәҗбүр булган чит ил татарлары безгә караганда бәхетлерәк дигән фикерне җиткерә: чит илләрдә тырышлык һәм ныклы хезмәтләре белән әйбәт тормышта гомер кичергән татарлар туган җирләрендә кулларны богаулаган, авызны томалап куйган хакимиятнең ирексез тормышында уңышларга ирешә алмаслар иде. Менә шундадыр татарның фаҗигасе: милләтнең иң дигән кыз-уллары туган җирләрен ташлап, чит якларда яшәргә мәҗбүрләр! Ә бездә? Бездә димәк чын зыялылар катламы юк диярлек, чөнки аларны йә төрмәләргә ябалар, йә илдән куалар.

Мәкаләне Миргазиян ага Юнысның китабыннан өзек китереп тәмамлыйсы килә: «Мин синнән моны көтмәгән идем, Миргазиян, «Хәнифә апа турында матбугатка язам», дип йөрисең икән. Тере кеше турында хикәя язалармыни? Кеше турында аның эше сөйләсен, ә буш сүз мактанырга гына ярый ул. Акыллым, син үзеңне мактаган кешедән кач. Мактау кешенең иң кыйммәтле сыйфатын җуя. Мактау кызгану белән бер ул – кешенең дәрәҗәсен ваклый...» Күпме татар милләтеннән укымышлы, эшчән, бар яктан да уңган шәхесләр, чын зыялылар чыккан! Нихәтле аларның язмышлары михнәт-газапка, мыскыл-талауга дучар булган! Татар милләтен тарихның читенә күпме этеп төшерергә тырышканнар, ә хакыйкать барыбер төпсез океаннан калкып чыккандай барлыгын белгерткән. Кемнәр соң ул онытылган татар зыялылары дигән сорауга без хәтер китабына сыйдырырлык татар хәрбиләрен, галимнәрен, сәнгать ияләрен, фидакяр хезмәт куючыларны әйтергә тиешбез. Алар күп, чиксез күп, санап та бетермәслек, әмма һәрберсе искә алынырга, тарихта үз лаеклы урынын алырга тиеш!

Ландыш ГАБИТОВА,
Г.Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе студенты.

Айга карама
кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

20 май (шимбә). ***Шәүвәл аеның 30 нчы көне.2 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 4.15 сәгатьтә калка, 22.28 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.32 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Солы сөте

Панкреатиттан (ашказаны асты бизе ялкынсыну) болай дәваланып була. 100 г солыны дуршлагта юалар, эмальләнгән кәстрүлгә 1,5 л суга салалар, кайнап чыккач, сүрән утта 40 минут пешерәләр. Солыны агач тукмак белән изгәч, тагын 20 минут пешерәләр. Суынгач, берничә катлы марля аша сөзәләр. Суыткычта саклыйлар. Көненә 3-4 тапкыр, ашар алдыннан, 100 әр г эчәләр.

21 май (якшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 1нче көне.3 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында,4.39 сәгатьтә калка,23.41 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.36 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмау зарур.

Күзне саклыйк!

Күз өчен бигрәк тә А витамины файдалы, шунлыктан кишер ашарга кирәк. Нерв системасының нормаль эшләве өчен (ә күз – нерв йомгагы ул), В1 һәм В2 төркеме витаминнары таләп ителә. В1 витаминына ит, бавыр, арыш икмәге, бодай үсентеләре, чүпрә, соя, бәрәңге, яшелчәләр, ә В2 витаминына алма, сөт, эремчек, сыр, йомырка, чикләвек, ит бай. С витамины җитешмәсә, күз мускуллары зәгыйфьләнә. Күз нигездә аксымнан торганлыктан, протеинга бай ризык ашау файдалы. Иң сихәтлесе каражиләк, аңардагы биоген матдәләр күзнең челтәр катламын яңарта һәм күз күремен яхшырта. Дөрес, нәтиҗәсен тояр өчен көн саен кимендә 150 грамм каражиләк ашарга киңәш ителә.

22 май (дүшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 2нче көне.4 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 5.16 сәгатьтә калка, 0.37 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16. 38 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди әлемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Лимонлы-баллы су

1 стакан минераль суда 1 аш кашыгы бал эретәләр, ярты лимон согын өстиләр дә, ач карынга эчәләр. Дәва курсы – 7-10 көн. Мондый шифалы су кан басымын төшерә, ярсуны баса, йокысызлыктан булыша.

23 май (сишәмбе). ***Зөлкагдә аеның 3нче көне.5 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында,6.09 сәгатьтә калка, 1.15***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карап кырын карама

сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.42 сәгать.

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь. Ай Кыслада чакта сизгерлек көчәя, кешедә психолог сәләте уяна, ул башкаларны сүзсез дә аңлый башлый.

24 май (чәршәмбе). ***Зөлкагдә аеның 4 нче көне.6 нчы Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 7.16 сәгатьтә калка,1.18 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.45 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Сихәтле май

Көннәр җылыткач, чебен-черки үзәккә үтә. Канечкеч бөҗәкләр тешләгән урын кызара, кычыта, шешә. Бу урынга лимон мае сөртү килешә. 1 лимонны юка телемнәргә турап, пыяла банкага тутыралар да, өстенә 150 мл чистартылмаган көнбагыш мае салып, караңгы урында бер атна төнәтәләр, көн саен болгаткалап алалар. Аннан соң марля аша сөзеп, суыткычта саклыйлар.

25 май (пәнҗешәмбе). ***Зөлкагдә аеның 5 нче көне.7 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 8.32 сәгатьтә калка, 1.54 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 16.48 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Дәфнә чәе

Кандагы шикәр микъдарын киметү өчен, 2 дәфнә (лавр) яфрагын 1 стакан кайнар суда 15-20 минут төнәтәләр дә, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, яртышар стакан эчәләр. Диабеттан интегүчеләргә карри (куркум, кориандр, әнеч, кара борыч, утлавык үлән, имбир, кардамон кушылмасы) тәмләткече дә файдалы, ул инсулин алмашын яхшырта.

26 май (җомга). ***Зөлкагдә аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,11.08 сәгатьтә калка, 2.12 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 16.55 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Тәмле-татлы кекс

4 йомырканы ярты чәй кашыгы тоз белән күпертәләр, 400 г куертылган сөт, аннары 125 г он һәм 1 чәй кашыгы камыр көпшәкләндергеч кушып туглыйлар, 45 г эретелгән атланмай өстәп, яхшылап болгаталар да, пергамент җәелгән формага салып, 180 градуслы газ мичендә 25-30 минут пешерәләр.



Гимныбыз шагыйре

Радио-телевидениедән яки берәр тантаналы кичәдә республика гимны яңгыраса, аның авторларының берсе булган Рамазан Байтимеров күз алдына килеп баса. Конкурс нигезендә гимн тексты итеп Рамазан Муллагали улы Байтимеров шигыре сайлап алынган иде. Дөрес, шагыйрь Гәрәй Рәхим аларны редакцияләде, төзәтмәләр кертте. Әмма шигырьләрнең мәгънәсе, төп нигезе сакланып калды. Гимнның музыкасы композитор Рөстәм Яхин тарафыннан язылган.

Р.Байтимеров тумышы белән Башкортстаннан. Ул 1923 елның 5 апрелендә Стәрлетамак кантонының Исмәгыйль авылында (бүген Авыргазы районы) крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач Рамазан апасы янына Үзбәкстанга китә. Алар Каттакурганда яшиләр. Анда урта мәктәп булмый. Шуңа күрә Сәмәркандка йөреп укырга туры килә. Бик тыйнак гомер итәләр, хәтта еш кына электричкага билет алырга да акчалары булмый. Рамазанга поезд түбәсендә йөрергә туры килә.

Гомуми урта белем алганнан соң Р. Байтимеров Ташкентта берьеллык педагогика курсларында укый. Әмма эшкә урнашырга өлгерми. Бөек Ватан сугышы башлана. 1941 елның көзендә Рамазанны солдатка алалар. Яшь солдат һава десантчысы була, йөзләрчә тапкыр парашюттан сикерә. Башта ул Мәскәүне фашистлардан азат итү өчен сугыша. Аннары аны Иранга җибәрәләр, махсус задание башкарырга туры килә. 1943 елда радиотелеграфистлар төркемендә Балтыйк буе территориясендә, Венгриядә, Чехословакиядә сугыша. Берничә тапкыр яралана, күрсәткән батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә.

Сугыш истәлекләре күп җыела. Әмма аларны кәгазьгә салырга вакыт булмый. Бары тик сугыш тәмамлангач кына, кулына каләм ала ул. 1945 елның ноябрендә Р.Байтимеров туган авылына инвалид булып кайта, берничә контузиясе дә була. Әмма боларга да бик борчылмый солдат. Язмыш аны ут эченнән исән-имин алып чыга. Ә ике абыйсы белән башка очраша алмый инде. Алар сугыш кырында ятып кала.

Р.Байтимеровның беренче шигырьләре Башкортстанның «Кызыл таң» газетасында басыла. Шулай да ул яшь вакытта югары белем алу турында хыяллана. Шушы теләге аны Казанга, дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә. Университетны да уңышлы тәмамлый. Аннары Рамазан «Чаян» журналында, Татарстанның радио һәм телевидениесендә эшли, мәктәптә дә укыта.

Төп эшеннән буш вакытларда Р.Байтимеров башы-аягы белән иҗатка чума. Шигырьләр, поэмалар, пьесалар иҗат итә. Аның әсәрләрендә Бөек Ватан сугышы күренешләре, туган як, беренче чиратта нефтьчеләр тормышы чагыла.

Р.Байтимеровның «Якты юл», «Ялгыз Бану», «Девон җыры», «Уңыш җыры», «Тере мәет», «Ике батыр», «Укытучы», «Тормыш хакына», «Орбита читендә», «Дипломат», «Сәлимә» пьесалары күп кенә театрларда яратып куела һәм карала. Язылуларына инде шактый вакыт үтсә дә, алар һаман да әле актуальлекләрен югалтмый.

Авторның берничә сайланма әсәрләр китаплары да дөнья күрде. Алар арасында 1982 елда чыккан шигырьләр һәм җырлар җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты), 1983 елда шушы ук нәшриятта басылган «Минем җырларым – солдатлар», 1986 елда поэмалардан һәм шигырьләрдән торган «Минем канатларым» җыентыклары бар. 1988 елда Бөгелмәдә ике актлы «Мәңгелек яшьлек» тарихи драмасы чыга.

Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова, Җәүдәт Фәйзи, Бату Мөлеков, Луиза Хәйретдинова, Рәшит Абдуллин, Исмай Шәмсетдинов кебек күренекле композиторлар Р.Байтимеров сүзләренә күп кенә җырлар яздылар. Алар бүген дә танылган җырчыларның репертуарында әле.

1958 елда һөнәре буенча укытучы хатыны Мөнәвәрә һәм ике кызлары – Гөлнур, Гөлшат белән бергә Рамазан, даими яшәү өчен, Лениногорскига юл тота. Ул район газетасында фотограф булып эшли башлый. Бөтен вакыты авылларда үтә. Тормышлары шактый авыр булса да, гаилә Лениногорскидан китми. Тик ни кызганыч, Р. Байтимеров биредә озак яши алмый. Бер-бер артлы инфаркт кичерә. Өченче инфаркт аны 65 яшендә, кичен чаңгыда йөрергә чыккач, фани дөньядан китә. Быел Р. Байтимеровның тууына 100 ел тулды. Гимн авторының әлеге юбилеен лаеклы билгеләп үтәсе иде.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

19 май – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
20 май – 12.00 – «Килмешәк» (С.Гаффарова). Шәрык клубында 15.00 – «Бичара кыз...» (Г.Ильяси). Зур залда – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев).
21 май – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
22 май – Язучы Рабит Батулланың юбилей кичәсе.
23 май – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).
24 май – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
25 май – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
26 май – «Санаулы кичләр» (А.Володин). Артист Минвәли Габдуллинның юбилей кичәсе.

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

12-30 май – Р.Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивале
19 май – «Анюта» (В.Гаврилин).
20 май – «Жизель» (А.Адан).
22 май – «Баядерка» (Л.Минкус).
24 май – «Дон Кихот» (Л.Минкус).
26 май – «Анна Каренина» (П.Чайковский).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

19 май – «Ашина» (Р.Зәйдулла).
20 май – «Кара пулат» (Р.Харис либреттосы).
24, 25 май – Премьера. «Җилкәнсезләр» (К.Тинчурин).
26 май – «Кияүләр» (Х.Вахит).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

19 май – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).
21 май – «ӘйдәБас» татар биюе фестиваленең гала-концерты.
23 май – 13.00 – Сәхнә арты буйлап сәяхәт. 18.30 – «12 адым» (Б.Минкин).
25 май – 13.00 – Сәхнә арты буйлап сәяхәт. 18.30 – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
26 май – «Корт» (Ф.Галиев).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

19 май – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән).
20 май – Зур залда – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән). Кече залда – «Кәҗә белән сарык» (Г.Тукай).
21 май – Зур залда – «Цветик-семицветик (В.Катаев). Кече залда – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
23 май – Фойеда – «Бобровый пруд».
25 май – «Маугли» (Р.Киплинг).
26 май – 11.00 – «Маугли» (Р.Киплинг). 18.30 – «Ханума» (А.Цагарели).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

24 май – «Дон Кихот» балеты (Л.Минкус).
25 май – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

20 май – С.Рахманинов исемендәге XII халыкара «Ак сирин» фестивале кысаларында Татарстан дәүләт симфоник оркестры концерты. Дирижер – А.Сладковский. Солист – Д.Мацуев.
24 май – С.Рахманинов исемендәге XII халыкара «Ак сирин» фестивале кысаларында Татарстан дәүләт симфоник оркестры концерты. Дирижер – Кристиан Кнапп. Солист – Ева Геворгян.
26 май – Чаллыдан Игорь Лерманның камера оркестры һәм Г.Гыймаева җитәкчелегендәге «Гармония» камера хоры концерты.

Борынгы кеше фикеренчә, туу ул – чыгу, үлем – керү. Авызга керү, ерткыч авызына, җылан авызына керү, ягъни ашалу. Кешенең менә шул мәңгелек фәлсәфәсен, төп карашын бик күп дәлилләр белән исбатлап була. Төрле халыклардан тупланган этнографик мисаллар ярдәмендә шушы фикерне ачыклыйк.

Нурихан ФӘТТАХ

Өйләнешү йолалары

Өйләнешүгә кагылышлы йолалар һәм гореф-гадәтләр арасында күпчелек халыклар өчен уртак булган кайбер моментлар бар. Берсе шул: балигъ булган яшь егет үзенең кан кардәшенә өйләнә алмый. Шулай ук балигъ булган кыз да үзенең кан-кардәшенә кияүгә чыга алмый. Фәнни әдәбиятта моны экзогамия дип атыйлар. «Экзогамиянең ничек итеп барлыкка килүе мәсьәләсе бүгенгә кадәр хәл ителмәгән», – дип яза Д.А.Ольдерогетте.

Экзогамия буенча, өйләнүчеләрнең икесе дә һичшиксез ике кабиләдән, ике ырудан булырга тиеш. Ыру-кабиләләр гадәттә берничә төркемгә бүленә. Мондый төркемнәрне этнографиядә клан, фратрия һ.б. атамалар белән атыйлар. Мәсәлән, Көньяк Һиндстандагы веддаларда ыру варуга дип аталган тугыз төркемгә бүленә. Һәр варуга икенче варугадан аерым яши һәм үз төркемен мөстәкыйль төркем дип исәпли.

Бер ыру эчендәге яшьләр өйләнешкәндә һичшиксез ике төркем (клан, фратрия, варуга һ.б.) кешеләре булырга тиеш. Ләкин кайбер халыкларда бер төркем яшьләре дә өйләнешергә мөмкин. Бу вакытта алар ике гаилә кешеләре була. Тува егете өйләнергә исәпләсә, аңа үз авылыннан кыз алырга ярамый, кыз күрше авылдан булырга тиеш. Семипалатинск өлкәсе казахларында элек кызны 700 чакрым читтән, хәтта аннан да ераграк авыллардан ала торган булганнар.

Өйләнешүчеләр ике ырудан яисә ике кланнан булырга тиеш дигән кагыйдәне без борынгы кешенең «күрше-дошман» дигән карашы нигезендә аңлатабыз.

Күрше ыру-кабиләләрнең туктаусыз сугышып торулары турында сөйләгәндә без йола сугышларын искә төшерәбез. Йола сугышларында каршы яклар бары тик бер-берсенең канын коюю һәм шул рәвешчә вак-төяк үпкәләрен, бәхәсле нәрсәләрен хәл итү өчен бәрелешә. Ләкин борынгы сугышларның башка төрләләре дә булган. Шундый низагларның иң таралганы һәм бүгенгә кадәр сакланып калганы – хатын-кыз өчен сугышу.

Сугышның бу төре вакытында бер ыру-кабиләнең яшь ирләре, бернинди сәбәпсез, икенче ыру-кабиләгә яу белән бара, аның сугышчыларын үтерә яисә аларны качарга мәҗбүр итә. Җиңүче як бары хатын-кызларны гына үтерми. Җиңүчеләр, кызларны һәм яшь хатыннарны әсир итеп, үз ыру-кабиләләренә алып китә. Махсус хатын-кыз яулау өчен генә булмаган башка төрле зур сугышларда да җиңүче як ирләре иң элек хатын-кызларны кулга төшерергә тырыша.

Кызны читтән, күршедән, «дошман»нан алуның иң әүвәлге формасы, шулай итеп, хатынкызны сугышта яулау, әсир итеп алу булган дип әйтә алабыз. Соңга таба гадәткә әйләнгән бу борынгы практика калдыкларын төрле халыкларның туй һәм өйләнешү йолаларында күрергә була.

XIII гасыр монголларында кияүгә биреләсе кыз, үзенең кемгә бирeлачәген белгәч, берәр туган-тумачасының өенә качып китә. Аңа өйләнәсе егет үзенең дуслары белән аны эзләп йөри. Кызны тапкач, ул аны көч куланып алырга һәм үз өенә көчләп иярткән кебек алып кайтырга тиеш булган.

XX гасырда монгол йоласы бераз үзгәрәк. Кәләшне аның ата-анасы йортыннан кияүнең дус егетләре алып китә. Ләкин киткәндә аның башына плащ («цуб») каплыйлар. Кәләш атка атлангач, аның артына атка бер кияү егете атлана һәм кызны арттан тотып бара.

Кызны читтән, дошман яктан сугышып, яулап алуга ишарәли торган кайбер детальләр төрки халыкларның туй йолаларында да сакланып калган. Казахларда кызның качу йоласы бар. Качкан кызны кияү егетләре төркемләшеп эзләп таба һәм кызның туганнары, якыннары белән кияү егетләре арасында көрәш барлыкка килә. Кәләш өчен көрәш йоласы төрекмәннәрдә дә бар. Төрекмәннәрнең мурчали, гоклен, тәкә кабиләләрендә кәләш өчен кияү һәм кыз яклы хатын-кызлар көрәшә. Кайчагында, кәләш дөягә менеп утыргач, озатып калучылар кызга таш, таяк, балчык бәреп кала. Төркмәннәрнең сарык кабиләсендә кияүне кыз өенә алып барганда ул (кияү) каршылык күрсәтергә тиеш. Салыр, мурчали һәм сарыкларда кияү туй буласы өйдәге барлык кешеләрне камчылап чыга. Тәкәләрдә кияү үзенең яшь хатынына аягы белән тибә. XX гасыр башларында Ирандагы төркмәннәрнең йомул һәм тәкә кабиләләрендә яшь кияү, үзенең булачак хатыны янына керер алдыннан, өй эчендәге һәм ишегалдындагы теләсә кемне камчыларга тиеш булган.

Себер татарлары кияү йортында кызны мылтык атып каршылый, кыз утырган арбага чүлмәк бәреп вата. Каргалы мишәрләрендә, кияү йортына килен төшкәч, шулай ук мылтык аталар. Казан татарларында егет, кыз куенына кергәч, тәлинкә, тәлинкә өстенә мендәр куелган урындыкка утырырга тиеш була. Кайбер кияүләр урындыкны

аяклары белән тибеп аудара һәм тәлинкә ватыла. Икәүдән-икәү калгач, йола буенча, кыз кияүне чишендерергә тиеш. Шул ук вакытта кайбер кияүләр булачак хатыннарын камчы белән сыдырган.

Татар телендә ЯУ сүзе дошман, сугыш, каршы як (враг, противник, бой, битва) мәгънәләрен белдерә. ЯУ сүзе ярдәмендә ясалган ЯУЧЫ (ягъни ЯУ остасы) – димче (сват, сваха) дигәнне аңлата. Өйләнүнең иң әүвәлге формасы – яу, сугыш яисә яу, сугышның нәтиҗәсе өйләнешү икәнлеген күрсәтү өчен моннан да отышлырак мисалны табып та булмас кебек.

Шулай итеп, өйләнешүнең бер төре, аерым алганда, читтәге, күрше ырудагы кызга өйләнү, һәм шулай ук читтәге, күрше ырудагы егеткә кияүгә чыгу йоласы борынгы заманнарда ыру-кабиләләрнең туктаусыз сугышып, дошманлашып торуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип әйтә алабыз.

Әгәр дә мәгәр дөньядагы барлык ыру-кабиләләр менә шул рәвешле генә өйләнешә торган булса һәм үзара сугышып тора торган булса, кешелек җәмгыяте, күрәсең, әллә ни үсешкә ирешә алмаган булыр иде. Әйтергә кирәк, Америкадагы, Азия, Африкадагы һ.б. континентлардагы бик күп ыру-кабиләләр, менә шушы бик борынгы йола һәм гадәтләрдән арына алмыйча, гасырлар буенча кыргый яисә ярым кыргый хәлдә кала биргән.

Хатын-кыз өчен туктаусыз кан коюның зарарын борынгы кеше дә аңлаган, әлбәттә. Һәм шушы аңлау нәтиҗәсендә, күрәсең, төрле яулардан, сугышлардан котылу юлы уйлап табылган. Яу куркынычы вакытында исән калу һәм кирәкмәгәнгә кан коюны булдырмау өчен, бер як икенче якка үзе теләп хатыннарын биреп торган. Австралиянең кайбер кабиләләрендә яу вакытында нәкъ менә шулай эшләгәннәр дә: көчсезрәк ыру кешеләре һөҗүм итүчеләргә үзләренең хатыннарын биреп торганнар. Һөҗүм итүчеләр, хатыннарны кабул итеп, аларны үзләре янында калдырса, сугыш булмаган. Һөҗүмгә дучар булган кабиләнең ирләре дә, хатыннары да исән калган.

Шулай итеп, иң элек бер ыру-кабиләнең ирләре күмәкләшеп күрше ыру-кабилә хатыннарын, кызларын яулап, сугышып ала. Соңга таба көчлерәк ыру-кабилә ирләре күрше (дошман) ыру-кабилә хатыннарын, кызларын яу белән куркытып, вакытлыча алып тора йә булмаса кайбер хатын-кызларны сайлап үз ыруларына, кабиләләренә алып китә. Тора-бара күрше кабилә ирләре күмәкләшеп түгел, бәлки аерым (индивидуаль) рәвештә бер-берсеннән кыз ала башлый. Ләкин аерым ир кеше өчен кыз алганда да, алучының ырудашлары, туганнары, дуслары бу эшкә катнашырга мөмкин. Бүгенге көндә татарларда һәм башка халыкларда сакланып калган кыз урлау йоласын әлеге индивидуаль яулап алуның бер күренеше дип карарга кирәк.

Дошманлашучы ике яисә берничә ыру арасында элемтәләр көчәйгәч һәм күршедән курку, шулай ук дошманлык тойгылары йомшагач, кыз алышу, кыз бирешү башкачарак кагыйдәләргә буйсына башлаган. Бу вакытта башка ыру-кабиләләрдән алынасы кыз яки егет өчен түләү йоласы барлыкка килә. Читтән, күршедән кыз алган өчен түләнелә торган акчаны, байлыкны татарча калым дип атыйлар.

Читтән кыз алган өчен калым түләү йоласы күпчелек халыкларда бар. Калымның күләме ике якның килешүе буенча билгеләнә. Калымга мал-туар, акча һ.б. нәрсәләр керергә мөмкин. Х гасырда угызларда кыз өчен калымга кием-салым, дөя түләгәннәр. Эвенклар кыз өчен болан биргән. Тамберма кабиләсендә өйләнүче егет башка кабиләдән алган кыз өчен 21 кәрзин тары яисә 4 сыер түләргә тиеш. Кайбер очракта булачак кияү калым исәбенә кызның ата-анасының берәр эшен эшләргә мөмкин.

Өйләнгәндә кыз яисә хатын өчен калым түләү ул кызны яисә хатынны сатып алу дигән сүз. Кайбер борынгы халыкларда алиһәләргә багышланган кызларның акча бәрабәренә чит ил кешеләренә бирелүе, ягъни дини проституция белән шөгыльләнүләре кыз өчен калым түләүнең бер төре булып тора. Күрәсең, кешенең иң беренче сату-алу эше белән шөгыльләнә башлавы, байлык туплавы һәм ахыр чиктә шәһәрләрнең, дәүләтләрнең барлыкка килүе – барысы да менә шундый «калым алу» нигезендә генә мөмкин булгандыр. Мисыр һәм Вавилон кешеләренең атаклы корылмалары белән чагыштырырлык дәрәҗәдә булган Алиат курганының (төрбәсенең?) күпчелек өлеше кызлар акчасына салынган, дип Геродот юкка гына әйтмәгәндер, ахры. Шул ук Геродотның язуына караганда, Фракиядән китерелгән кол Родопис Мисырда үз һөнәре белән шөгыльләнеп, бик күп байлык җыйган һәм шуның акчасына, имеш, үзе өчен пирамида салдырган.

Дөрес туклану мөһимме?

Мөгаен, йөзьяшәрләргә иң күп бирелгән сорау аларның туклану рәвеше турындадыр. Тик аларның җаваплары төрле. Көньяк Калифорния университеты каршындагы Озын гомерлелек институты директоры Вальтер Лонго бу турыда: “Йөз кешедән сорасагыз, йөз төрле тарих ишетерсез”, – дигән. Тик шулай да кызыклы диеталар да очраштыргалый. Мәсәлән, 117 ел яшәгән Эмма Морано көн саен өч чи йомырка эчкән. Бу сәер гадәтнең аңлатмасы бик гади: доктор аңа анемиядән дәвалану өчен шундый киңәш биргән. Эмма үлгәнче әлеге киңәшкә тугры булып калган һәм гомере буена йөз меңнән артык йомырка эчкән, мөгаен, тарихта мондый кеше бүтән юктыр. Ямайкадан 117 яшьлек Вайолет Мосс Браун беркайчан да тавык һәм дуңгыз ите ашамаган, ром эчмәгән. Америкадан 100 яшьлек Флоренс Беарс бер тапкыр да казылык ашамаган. Франциядә йөз яше тулгач та бармен булып эшләвен дәвам иткән Мари-Лу Вирт витаминнарны кулралмаган – ул беркайчан да җиләк-җимеш ашамаган, сөт яки йогырт эчмәгән, бары тик чиста су гына яки чамасын югалтмыйча хәмер эчкән. 2013 елда 116 яшендә бакыйлыкка күчкән япон Дзироэмон Кимура озак яшәү өчен чаманы югалтмаска өндәгән. Ә менә 1997 елда 122 яшендә вафат булган француз хатыны Жанна Кальман бер атнада бер килограмм шоколад ашый торган булган. Америкада 109 яшьлек Руфь Бенджамин көн саен бекон белән бәрәңге кыздырып сыйланган. 103 яшен тутырган Дороти Флетчер исә көн саен фастфуд ашаган һәм үзенең озак яшәү сере нәкъ менә чизбургерда, дип уйлаган.

(“The Mirror”).

Даһимы, юкмы?

Владимир Ленинның күп кенә көрәштәшләре, ул гайре табигый акыл сәләтенә ия, аның башында ми түгел, бәлки, Николай Бухарин әйтүенчә, “куәтле баш аппараты”, дип уйлаган. Дөнья пролетариаты юлбашчысының баш миен җентекләп өйрәнеп, шуның нигезендә даһи кешеләр селекциясе буенча материал эшләргә өндәүчеләр дә булган. Шунлыктан Ленинның вафатыннан соң аның тәненнән баш мие һәм йөрәгенең алынуы гаҗәп түгел. Хакыйкатьне табу өчен, мине бик нечкә кисемнәргә бүлеп, микроскоп астында тикшерергә җыенганнар. Моның өчен 1925 елда Мәскәүгә Германиядән дөньякүләм танылган невропатолог Оскар Фоггны чакырып китергәннәр, аның лабораториясен күчергәннәр. Галим юлбашчының даһи акыл сәләтен матди нигезләргә тиеш булган. Ул Ленинның баш миен 31 мең кисемгә бүлгән һәм шуларның һәркайсын гади кеше мие белән чагыштырган. 1929 елда Фогг, Ильичның акыллы булуының сере ми кабыгының өченче катламында, дип белдергән, янәсе, андагы пирамидаль күзәнәкләр башкаларныкына караганда күпкә күчлерәк үскән. Германиядә исә Фоггның тикшеренү нәтиҗәләрен тәнкыйтьләгәннәр, аларны бөтенләй фәнни түгел, дип тапканнар. Хәер, хәзерге фән дә баш мие структурасы буенча кешенең теге яки бу сәләте турында хөкем чыгарып булмый, дип саный.

(“Interesnik.net”).

Барыбер әйләнә!

Барыбызга да мәктәп программасыннан таныш уйдырмаларның берсе Галилео Галилей турында. Имеш, ул үзенең хаксызлыгын таныган, инквизиция хөкеме белән килешкән, әмма җәзалану алдыннан: “Ә ул барыбер әйләнә!” – дип әйтеп өлгергән. Чынлыкта исә әлеге гыйбарә Галилей хөкем ителгәннән соң 120 ел үткәч кенә пәйда булган. Инквизиция исә галимнән геоцентризм теориясен тануны таләп тә итмәгән.

Әкиятме, чынбарлыкмы?

